Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең
Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институты

# ИҖТИҺАД ИШЕКЛӘРЕН АЧУЧЫ
# МӘРҖАНИ

Мәкаләләр җыентыгы

Казан – 2018

УДК 28
ББК 86.38
И 98

**Фәнни мөхәррир:**
ТР ФА академигы, тарих фәннәре докторы *Р.С. Хәкимов*

**Төзүче:**
филология фәннәре кандидаты *А.М. Гайнетдинов*

**Иҗтиһад ишекләрен ачучы Мәрҗани:** Мәкаләләр җыентыгы / Төз. А.М. Гайнетдинов. – Казан: ТР ФА Ш. Мәрҗани исем. Тарих институты, 2018. – 76 б.

ISBN 978-5-94981-290-7

Китапта күренекле татар галиме Шиһабетдин Мәрҗанигә багышланган төрле мәкаләләр урын алган. Алар, галимнең замандашлары һәм шәкертләре тарафыннан язылып, инкыйлабка кадәр чыккан «Аң», «Шура», «Йолдыз», «Кояш» дигән газета-журналларда басылган. Хезмәтебез галимнәргә, мөгаллимнәргә, дин әһелләренә, гомумән, татар халкының тарихы һәм дини мирасы белән кызыксынучы укучыларга тәкъдим ителә.

ISBN 978-5-94981-290-7 УДК 28
ББК 86.38

© Гайнетдинов А.М., 2018
© ТР ФА Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институты, 2018

# Кереш

Шиһабетдин Мәрҗани (1818–1889) – бөтен көчен милләтебез, динебез өчен сарыф итеп, армый-талмый хезмәт куйган бөек татар галиме, тарихчы, дини реформатор, педагог, этнограф, эпиграфист, шәркыять белгече, җәмәгать эшлеклесе, җәдидчелек хәрәкәтенең күренекле вәкиле. Быел аның олуг юбилее җитте, ягъни 2018 елда тууына 200 ел булды. Шулхәтле күп вакыт узса да, бу шәхеснең исеме һаман телләрдән, каләмнәрдән төшми, халкыбыз аны һәрвакыт горурланып искә ала, хәзерге фәндә дә татарның иң бөек һәм могтәбәр галиме буларак санала.

Ш. Мәрҗанинең олуг хезмәтләре бөтен ислам галәмен диярлек тетрәндергән һәм уйланырга мәҗбүр иткән. Ул халыкны аңбелемгә, иҗтиһадка (шәригать мәсьәләләрен үзлектән тикшереп, мөстәкыйль фикер йөртүгә) чакырган һәм схоластикадан, тәкълидтән (элекке дин галимнәренә сукырларча иярүдән) арынырга өндәгән. Җәдидче галимебез тышкы кыяфәте белән башка дин әһелләре кебек булса да, үзенең эчке рухи дөньясы, дини карашлары белән алардан нык аерылып торган. Ул акылы булган һәр кешене, «иҗтиһад ишекләре»н ачып, Коръән һәм хәдисләр белән шәригать мәсьәләләрен үзлегеннән тикшереп, нәтиҗә чыгарырга, мөстәкыйль фикер йөртергә, исламны төрле әкиятхорафатлардан, элекке галимнәрнең ялгыш фикерләреннән арындырып, динне тормыш һәм фән белән бәйләргә чакырган.

Мәрҗанинең мөселманнарны тәкълид бәласеннән коткарган «Назүрәтел-хак» әсәре, гомумән алганда, ястү намазының җәйге көннәрдә дә өстән төшмәве, шәфәкъ кызыллыгы бетмәсә дә,

барыбер аны уку мәҗбүри икәнен исбат итүдән гыйбарәт. Ләкин бу мәсьәләгә карата җавабын язу алдыннан Мәрҗани бик озын кереш өлеш язган һәм менә шунда аның инкыйлаби фикерләре мәйданга чыккан, халыкны сукырларча дини мәзһәбләргә ияреrgә түгел, ә, бәлки, исламның төп чыганаклары булган Коръән һәм хәдисләрдән дәлил тапканнан соң гына теге яки бу гамәлне яки гыйбадәтне үтәү тиешле икәнен исбатлаган. Әлеге хезмәтнең асыл кыйммәте төп өлешендә түгел, ә озын мөкаддимәсендә (кереш өлешендә), ягъни китапның беренче алтмыш битендә. Шуңа күрә Г. Ибраһимов түбәндәгечә яза: «Мөкаддимәдәге фикерне берничә сүздә җыярга туры килсә: Аллаһ азат яраткан акылга богау салмагыз, мөэминнең фикере хөр, менә Коръән, менә хәдис – шуларны өйрәнсен дә үзе аңлаганча ышансын вә гамәл кылсын. Мин үземнең һичкемнең фикер һәм мәзһәбенә ияреrgә мәҗбүрмен дип белмим... рәвешендә нәтиҗә ясарга мөмкин иде»[1].

Шиһабетдин хәзрәт – бөтен ислам дөньясын тәкълид бәласеннән коткаручы, дини фикердә инкыйлаб ясаучы шәхес. Дөрес, аңа хәтле Габденнасыйр Курсави инде XIX гасыр башында ук халыкның акылына салынган богауларны өзәргә тырышкан, тик аның халыкка тәэсире алай ук көчле булмаган. Үзләренең ирекле карашлары өчен аларның икесенә дә кадимчеләр тарафыннан «кяфер», «имансыз» мөһере сугылган иде.

Мәгълүм ки, элекке мәдрәсәләрдә схоластик белемнәр биргәннәр, урта гасырда яшәгән галимнәрнең сүзләренә сукырларча ияреrgә өйрәткәннәр, төрле гыйбарәләрне аңламыйча, фикерләмичә, ятлату белән мәшгуль булганнар. Мәсәлән, игътикад (иман) өлкәсендә әшгари яки матүриди (Әбү Хәсән

[1] Ибраһимов Г. Бөек остазымызның кайбер тәэлифләре. Юбилей мөнәсәбәте илә тәнкыйть / Г. Ибраһимов // Аң. – 1915. – № 1. – Б. 13.

Әшгари, Әбү Мансур Матүриди атлы галимнәргә иярүче) фикыһ (ислам хокукы) өлкәсендә хәнәфи (Әбү Хәнифә исемле галимгә иярүче) мәзһәбенә иярүне мәҗбүри итеп куйганнар, моны эшләмәүчеләрне җәһәннәм белән куркытканнар. Г. Ибраһимов язганча, элекке кадимче мөдәррисләр «әшгари», «хәнәфи» сүзләре белән шәкертләрнең йөрәкләрен һәм акылларын томалаганнар: ««Бисмилла», «Аллаһ», «Коръән» сүзләре белән янәшә өйрәтелгән ул «әшгари», «хәнәфи» сүзләре безгә, бер безгә генә түгел, һәр мөселман баласына җиде яшьтән керә башлап, мохитнең тәэсир итә баруы белән алар йөрәкнең төбенә кадәр тамыр җәеп, бөтен гакли хәятны каплап ятканнар»[2]. Шунысы аяныч: хәзерге заман мәдрәсәләребездә дә, матүриди һәм хәнәфи мәзһәбләренә сукырларча иярүне таләп итеп, шәкертләрнең йөрәкләренә һәм акылларына кабат тәкълид богавы сала башладылар, хәтта бүген кайбер дин әһелләре кадимчеләрдән әллә ни аерылмыйлар сыман. Юкка гына тырыштымыни Мәрҗаниебез?!

Бөек реформатор Шиһабетдин хәзрәт югарыда искә алынган мәсьәләләрне күтәреп, кешеләрнең дини авторитетларга сукырларча иярүен нык тәнкыйтьләгән, иҗтиһадка чакырган, тәкълидтән тыйган. Ул заманда, Коръән-хәдисне гади кешегә аңларга һәм аларга мәгънә бирергә ярамый, дигән фикер куәтле булса да, Мәрҗани иҗтиһад капкаларын ачкан һәм башкаларны да шул капкадан керергә чакырган. Моның өчен һичшиксез Коръәнне, йөзләгән хәдисләрне яттан белү таләп ителмәвен аңлатырга тырышкан; ислам чыганакларын белгән мөселман үзе үк галим-мөҗтәһидкә әйләнә һәм шәригать мәсьәләләрен үзе тикшереп, мөстәкыйль фикер йөртә, нәтиҗә ясый ала, дип

[2] Ибраһимов Г. Бөек остазымызның кайбер тәэлифләре. Юбилей мөнәсәбәте илә тәнкыйть / Г. Ибраһимов // Аң. – 1915. – № 1. – Б. 13.

санаган. Шуңа күрә Әхмәдһади Максуди, Ш. Мәрҗанинең чын мөҗтәһид булуын һәм аның әшгари белән матүридигә бернинди катнашы булмаганлыгын белдереп, түбәндәгечә язган: «Мәрҗани хәзрәтләре бөтен ислам галәме тәкълид һәм тәсаувыф (суфичылык) бәлаләренә дучар булган бер заманда пәйда булып, үз өлешенә төшкән вазыйфаны форсаты ярдәм иткән микъдарда тулысынча үтәде, кимчелек кылмады. Мәрхүм әдип түгел иде, шагыйрь дә түгел иде, суфи бер шәех тә булмады, философ та булмады, ләкин фикере куәтле һәм сәламәт фикер иясе бер шәргый мөҗтәһид иде. Игътикад бабында да тырышлык күрсәтте, мәгълүм булган гыйльми хөкемнәрне дә үз иҗтиһадына муафыйк булганлыгы өчен генә кабул итте. Игътикадта әшгари түгел, матуриди дә булмады, мөгътәзили яки шигый да түгел иде, ләкин Мәрҗани иде. Мәрҗанилеге дә Коръән вә Сөннәткә тулысынча иярүдән һәм болардан башкаларның һичберсенә дәлилсез иярмәүдән гыйбарәт иде»[3].

Мәшһүр татар галиме Ризаэтдин Фәхретдин гакыйдә китапларының әшгари белән матүриди мәзһәбләренең фикерләре белән тулганлыгына кайгырып, болай дип язып калдырган: «Ислам дөньясында «әһлес-сөннә вәл-җәмәга юнәләше» исеме белән укыла торган гакыйдә китапларының «әһлес-сөннә вәлҗәмәга юнәләше» булудан бигрәк, кәлям әһеле, ягъни әшгари һәм матүридиләр юлы икәнлеген, анда булган темаларның Коръән һәм Сөннәткә туры килүдән бигрәк тә, мөгътәзиләләрне кире кагуны нигез итеп алынганлыгын аңларга һәм шушы фикерне Аллаһ ризасы өчен һичкемнән курыкмый сөйләргә тиешле иде»[4]. Шулай ук ул, Әбү әл-Хәсән әл-Әшгари белән Әбү

[3] Мәрҗани: Фәнни-популяр җыентык. – Казан: Җыен, 2010. – Б. 453–454.
[4] Фәхретдин Р. Мәрҗани җыентыгына күзәтү / Р.Фәхретдин // Шура. – 1915. – №9. – Б. 285.

Мансур әл-Матуридигә иярүчеләр генә чын мөселман була, дип әйтүчеләрне надан кешеләргә тиңләгән[5].

Бүгенге көндә кадимчелекне яклаучылар, Мәрҗанине хәнәфилек белән тыгыз бәйләмәкче булып, аның хакында хаталы булган кайбер фикерләрне тараталар. Хәтта ни өчендер «Татар энциклопедия»сендә: «Мәрҗани, исламның гомуми нигезләмәләре хакында сүз кузгатканда, хәнәфи мәзһәбенә катгый рәвештә ияреpгә кушкан», – дип язылган[6]. Бу – әлбәттә, дөреслеккә туры килми, чөнки Шиһаб хәзрәт хезмәтләрендә, киресенчә, моның капма-каршысын белдергән: «Бер фәкыйһнең генә фәтваләрендә тукталып, аның мәсләгенә фанатикларча, тиешле дәлилләр белән дә нигезләмичә, ябышу ярамый»[7]; «Чынлыкта, әгәр дә берәр галимгә ияру һәм тәкълид кылу мәҗбүри булса, бу кешеләрне кысар, уңайсызландырыр иде. Кешеләрнең тулысынча галимнәргә иярүләрендә җиңеллек һәм киңлек юк»[8]; «Аларның (мәзһәбләргә нигез салучыларның) берсенең булса да: «Минем мәзһәбемә генә ияр», – дип әйтүе турында һичбер хәбәр дә килмәде, ә, бәлки, моның капма-каршысы гына килде»[9]; «Берәүгә дөрес хәдис иреште икән, ничек инде аңа: «Әбү Хәнифә, я Малик, я Шафигый, я Әхмәд, я

[5] Фәхреддин Р. Җәвамигыль-кәлим шәрехе / Р. Фәхреддин.- Оренбург, 1916. – Б. 110.
[6] Татарская энциклопедия: В 6 т. / Гл. ред. М.Х. Хасанов, отв. ред. Г.С. Сабирзянов. – Казань: Институт Татарской энциклопедии АН РТ, 2008. – Т. 4: М–П. – С. 74.
[7] Мәрҗани Ш. Назурәтел-хаккый фи фәрадыйятил-гыйшаи вә ин ләм ягыйбәш-шәфәкъ / Ш. Мәрҗани. – Казан: Хозур, 2013. – 336 б. (гарәп телендә). – Б. 68.
[8] Шунда ук. – Б. 69–70.
[9] Шунда ук. – Б. 321.

башка берәүнең фикерен белми торып, бу хәдис белән гамәл кыла күрмә», – дип әйтергә мөмкин?!»[10] һ.б.

Г. Ибраһимов, Р. Фәхретдин, Х. Габәши, Т. Ильяси, Һ. Атласи, Ш. Шәрәф, Г. Гыйсмәти һ.б. галимнәр Мәрҗанинең хәнәфи мәзһәбенә катгый рәвештә иярергә кушмаганлыгын, бәлки Коръән һәм Сөннәткә мөрәҗәгать итеп, һәр мөселманга иҗтиһад кылып, дини мәсьәләләрдә үзләренә җавап эзләргә боерганын әйтеп калдырганнар. Галим фәкать табигатьләре белән акыллары сай, фикерләүгә сәләтсез булган кешеләргә генә, чыгарма рәвешендә, нинди дә булса мәзһәбкә иярергә рөхсәт иткән[11].

Хәзерге заманда безгә Ш. Мәрҗани хезмәтләренең ни рәвешле көчле тәэсир иткәнлеген аңлавы кыен, аны фәкать шул чорда яшәгән мөселманнар гына бөек реформаторның батырлыгын, бөеклеген, олуг дәрәҗәсен хакыйкый рәвештә күрә һәм тоя алганнар. Ничә еллар буе фанатизм белән сугарылган бозык ышанулар зинданында ябылып яткан, соңра Мәрҗани аркасында азат ителгән бик күп дин әһелләре аның хезмәтләренә иң югары бәя биргәннәр, галимгә һәрвакыт рәхмәтле булганнар. Шуңа күрә бөтен ислам дөньясы аның исемен ихтирам белән телгә алган, халкыбыз да аны бик кадерле бер урынга утырткан. Мәсәлән, Г. Ибраһимов галимне түбәндәге сүзләр һәм эпитетлар белән искә алган: бөек остаз, куәтле мөтәфәккир (фикер иясе), җәсүр (кыю) бер каһарман, гаюр (горур) каһарман, фикри хәятта революция ясаучы, зур галим, яхшы атаның баласы, Казанның беренче мөдәррисе, таң чулпаны, иң куәтле мөәссир (тәэсир итүче), даһи, даһи акыл иясе, бөек мөхәккыйк (дөреслекне тикшерүче), тар рамкаларны ватучы, яңаны ясаучы, үзенә

[10] Мәрҗани Ш. Назурәтел-хаккый фи фәрадыйятил-гыйшаи вә ин ләм ягыйбәш-шәфәкъ / Ш. Мәрҗани. – Казан: Хозур, 2013. – 336 б. (гарәп телендә). – Б. 314.

[11] Шунда ук. – Б. 27.

кадәр булмаган нәрсәне тудыручы, милли тарихка нигез салучы, тарихыбызның мөҗиде (иҗат итүчесе) һ.б.

Галим хакында инде бик күп сөйләнелгән, язылган, хәтта инкыйлабка хәтле үк инде Ш. Мәрҗани хакында төрле газета-журналларда байтак мәкаләләр дөнья күргән. Аларның күбесе милләттәшләребезгә таныш та түгел. Бу инде аңлашыла да, беренчедән, алар гарәп графикасында, икенчедән, иске татар телендә, ягъни хәзерге телдән бераз аерыла торган телдә язылган. Шуларны истә тотып, без Г. Ибраһимов, Р. Фәхретдин, Б. Шәрәф, Г. Баттал, Г. Гыйсмәти, И. Габиди, Г. Гафуров, Г. Хәбиб, З. Кәримия кебек атаклы галимнәр, дин әһелләре, җәмәгать эшлеклеләре, замандашларының Мәрҗанигә багышланган кайбер мәкаләләрен кириллицага күчереп, аңларга уңайлы булсын өчен барлык архаик грамматик формаларны хәзерге әдәби тел нормаларына салып, милләттәшләребезгә тәкъдим итәргә булдык. Нәкъ менә гади халык укысын, аңласын өчен аларны хәзерге телгә яраклаштырып бирдек, ягъни максималь дәрәҗәдә хәзерге гамәлдәге телгә җайлаштырдык, якынайттык. Шулай ук текстларда очраган гарәп телендәге җөмләләр татар теленә тәрҗемә ителде. Бу китабыбыз аркылы укучылар Ш. Мәрҗани хакында тагын да күбрәк белерләр, дигән теләктә калабыз.

*А.М. Гайнетдинов*

*Галимҗан Ибраһимов*

# Бөек остазыбызның кайбер әсәрләре (юбилей мөнәсәбәте белән тәнкыйть)

## I. «Назурэтел-хак»

Әсәр шулай башлана: «Аллаһ Тәгаләгә мактау булсын, Аның күркәмлегенә һичбер күз дә, күрү сәләте аша ирешмәс. Аның камил барлыгына кем булса да акылы, уйлау-фикерләве белән ирешүдән чиксез өстен. Ул Үзенең колларыннан Үзеннән башка һичбер ышанып тапшыручы сайлап алмаска вәгъдә алды. Әйтте: «Җеннәрне һәм кешеләрне Миңа гыйбадәт кылсыннар өчен генә бар иттем. Мин алардан миңа ризык китерүләрен дә, Мине ашатуларын да теләмим, таләп итмим» [Коръән, 51:56–57]. Мин Аңа безгә чиксез нигъмәтләр биргән өчен, мактаулар әйтәм. Без үзебезгә нигъмәт бирүче турында шикләнүдән азат. Ул безне намазларын саклаучы иман ияләреннән итте. Мин аның илчесе булган, безгә «Каф» һәм «Нүн» сүрәләрен ирештергән сөекле Мөхәммәд галәйһиссәламгә сәламнәр һәм салаватлар әйтәм. Ул безгә ачык мәгънәле аятьләр китерде. Аларны бары тик караңгылыкта булган адашканнар гына инкяр итә. Шулай ук пәйгамбәрнең үзенә беренче ышанган һәм ярдәм иткән мөэмин сәхабәләренә сәлам-салаватларым булсын. Алар – «Ясин»не китерүче [пәйгамбәр] белән бергә авырлыкларны кичеп, аннан соң аның эшен дәвам итүчеләр. Шулай ук Фиргавен гаиләсендә булган мөэмингә дә сәлам-салаватларым булсын һ.б.».

Шул рәвешчә, нәкъ иске заманның мантыйк һәм кәлям[1] [китапларының] кереш сүзләре шикелле хәмд һәм саләттән соң, Аллаһның затын, гүзәллеген күз белән күрү мөмкин булмавын әйтә итә дә, бөтенләй иске, кыйммәт гарәп китапларындагыдай, җөмлә ахырларындагы рифмалы чәчмә сүзләрне дә хөрмәтләп, үзенең бу әсәрдә җентекләп аңлатачак мәсьәләләренә нечкә ишарәләр ясый, аннан соң тулы бер урта гасырларның шәрык язучысы сурәтендә: «Соңыннан: ярдәм сораучы кол әйтә», – дип, үзенең исемен, китап исемен әйткәннең соңында, асыл максатка якынлап дәвам итә: «Укый-яза белмәүче, тугры пәйгамбәрнең юлын нык кайгыртканы өчен Аллаһ аңа яхшы иярченнәр, эшен дәвам итүчеләр бирсен. Хаклыгы көн кебек ачык сүзләрне әйтә: хәбәрләрнең иң хәерлесе Аллаһ китабы, иң хәерле юл – Мөхәммәд галәйһиссәлам юлы, эшләрнең иң яманы – уйлап чыгарылган сүз, һәр уйлап чыгарылган сүз – бидгать[2], һәр бидгать – адашу. Чынлыкта, иң кабәхәт бидгатьләрнең берсе, уйлап чыгарылган сүзләрнең иң хурлыклысы», – дип, укучыларның зиһенендә үз дәгъвасына җирлек хәзерләгәннән соң, төп мәсьәләгә кагыла һәм йөрәгенә атылган бер әдәби бәхәсләшүче – полемик рәвешендә кинәт үзенең фикри дошманнарына һөҗүм белән ташлана: «Чынлыкта, иң кабәхәт бидгатьләрнең берсе, уйлап чыгарылган сүзләрнең иң хурлыклысы – өммәтнең кайбер вәкилләренең, ястү намазының кайбер илләрдә, ел әйләнәсендәге кайбер көннәрдә, төннең вакыты бик кыскарып, шәфәкънең бетмәве сәбәпле, өстән төшүе һәм ул намазның фарыз булмавы турындагы сүзләре. Бу – бидгатьләрнең иң куркынычы, олы афәт, күңел көенерлек хәл. Бу бидгатьне диннәрендә кайбер кимчелекле кешеләр башлап чыгарып, ул кабул ителеп, бик киң таралды һәм бик зур бер

[1] Кәлям – дини ышануларны акыл аша аңлатучы фән.
[2] Бидгать – догмат һәм гыйбадәт мәсьәләләрендә Коръән һәм пәйгамбәр өйрәтүләренә туры килмәгән фикерләр, гамәлләр, йолалар һәм сүзләр.

фетнәгә әйләнде. Күп халык аңа сукыр, надан рәвештә ияреп, шулай тиеш, дип уйлый башлады...».

Заманында булган шундый зур хата, шундый кабәхәт бидгатькә каршы булып, шул әсәрне язарга теләвен бәян иткәннән соң, тагын шулай, «Шәмсия» ияләренең: «Моны кереш, өч бүлек һәм йомгак итеп төзедем», – дигән кебек: «Мин үземнең китабымны кереш, эчтәлекле бүлекләр һәм йомгак белән сүз тәмамлаудан гыйбарәт иттем», – ди.

Гомумән әсәр үзенең стиле, тәртибе һәм бөтен тышкы кыяфәтләре белән моннан биш-ун гасыр элек Багдад яки Картабада язылган гарәп галимнәренең китапларыннан һичбер җәһәт белән аерылмый. Бу яклардан «Назурәтел-хак» – «Кәшфез-зонун»нарда исемнәре санап бетергесез гарәп әсәрләренең берсе, бертуганы. Әмма эчке ягына килгәндә, аның әйтергә теләгән фикере ягыннан каралса, монда сез бөтенләй башка рух хис кылачаксыз. Монда, кыскача әйткәндә, ислам дөньясын каплап, акылларны богаулап яткан барлык туңлыкларга, барлык фанатизм һәм каралыкларга каршы горур протест кылучы куәтле фикер иясен, фикердә һәм игътикадта[3] хөр булу – һәркемнең табигый хокукы, дип игълан итәр мәртәбәдә батыр бер каһарманны күрәчәксез». «Назурәтел-хак»ның безнең өчен иң кыйммәтле ягы да – шунда. «Назурә» очраклы яки чыгарма рәвештә килеп чыккан бер әсәр дә түгел. Ул Мәрҗани өчен табигый сурәттә барлыкка килгән бер китап. Тик монда язучының эчке дөньясы, аның протесты башка әсәрләренә карaганда ачыграк, куәтлерәк файдаланылган.

Гомумән, бу ике сыйфатта – иске кыяфәт эчендә яңа рух булуда – Мәрҗани белән аның әсәрләре арасында бик көчле ошаш[лык] бар.

Рәсемнәр безгә аны карт һәм мәһабәт дамеллалардан берсе итеп күрсәтәләр: башында Бохара шәрифчә итеп чалынган зур чалма, эчтән озын аксыл кәзәки, аякта читек, тыштан кама

[3] Игътикад – дини ышану системасы.

якалы һәйбәт намаз туны. Киемдә генә түгел, йөреш һәм торышның күбесендә дә ул безгә могтәбәр хәзрәтләрнең берсе булып күренә: без аны озын таяк тотып, мәчет капкасыннан кереп барган хәлдә, михрабда көйләп гарәпчә хөтбә укып торган сурәттә, бик иске гарәпчә китаплардан мендәргә тезләнеп «Тәүзыйх»тан дәрес биреп утырган рәвештә күз алдыбызга китерәбез. Гомумән, ул тышкы дөньясы, сурәте белән шундый бер дамелла иде. Ләкин аның рухани дөньясында без башка дамеллаларның һичберсенә охшамый торган бөтенләй башка, бөтенләй яңа, ул заманның фикри тормышына нисбәтле революция дип атарлык мәртәбәдә куәтле дулкыннар күрәбез.

Һәм, чыннан да, чалмасы, туны, кулындагы «Тәүзыйхы» белән башка хәзрәтләрнең берсе булган бу бөек зат үзенең фикри тормышы белән заманына күрә бөтенләй башка, ул моны үзе дә хис итә, үзеннән бигрәк, эчендә яшәгән мохите моны бигрәк ачык сизә һәм сиздерә иде.

Бүгенге кебек ачык хәтеремдә: кадим мәдрәсәдә чакта остазлар белән бер мәҗлестә заманның галимнәре хаккында сүз чыкты да, кемдер Кышкар дамелла Исмәгыйль белән Шиһаб хәзрәтне гыйльми яктан чагыштыра башлады. Шул вакыт остаз бик нечкә һәм бик гадел хаким сыйфаты белән: «Шиһаб хәзрәт, бәлки, галимдер, ләкин ул сәләф[4] юлыннан чыкты. Әмма дамелла Исмәгыйль бу турыда гаҗәеп бер адәм иде. Ул үзе гыйлемнең һәр бабында заманының бердәнбере булган хәлдә, сәләф юлыннан кыл кадәрле [дә] аерылмады, сәләфләр сүзенә һичбер хәреф каршы әйтмәде, изге сәләфләрдән бер сүз риваять кылынса, дамелла Исмәгыйль өчен ул сүз турында алай-болай фикер йөртү зур гөнаһ санала иде», – диде.

Ул вакыт[та] Мәрҗани кебек зур галимнең, алай сәләфкә каршы сөйләп үз кадерен үзе төшерүе өчен, аны чын күңелдән кызганган, кайберләребез аңа көфер мөһерләре дә баскан иде.

[4] Сәләф – борынгы мөселман галимнәре.

Менә бүген инде шул сыйфаты өчен бөтен ислам дөньясы аның исемен ихтирам белән телгә ала, шуның өчен аны халкыбызның прогрессив өлеше үзенең фикри үсешенең тарихында бик кадерле бер урынга утырта.

Борынгы ислам мәдәнияте тарихын язган чакта Мәрҗанинең «Мөкаддимә»се миңа, Җирҗи Зәйдан белән Күстәү-Ләбүннән кала, әһәмиятле чыганакларның берсе булды. Аның «Әл-бәркыль-вәмиз»ы, дини мәсьәләләргә караган тагын берничә әсәрләре мәдрәсәдә чакта бик дәрт белән укылды; ләкин аның әсәрләре эчендә, мәдрәсә галәменнән чыгып яңарган яшь буынга иң нык тәэсир биргәне «Назурәтел-хак». Әсәрнең тәмам исеме «Назурәтел-хак фи фәрзыятил-гыйша һәм ин ләм агый биш-шәфәкъ» [«Шәфәкъ кызыллыгы бетмәсә дә, төнге намазның фарызлыгы өстән төшмәве хакындагы хакыйкать телескобы»] булып, моңардан аңлашылганына күрә, бу китапны язуга башлыча сәбәп шул заманда бик күп бәхәсләр тудырган ястү [намазы] мәсьәләсе. Шәфәкъ батып җитмәс борын таң ата башлаган җирләрдә ястү фарызмы, түгелме? Бер як: «Түгел», – ди. Чөнки намазга вакыт шарт, шәфәкъ батмагач, вакыт кергән булмый, бәс, шарт табылмый, шартның юклыгы – шарт ителгәннең юклыгына сәбәпче – бәс, ул җирләрдә җәйнең кыска төннәрендә ястү юкка чыга.

Шәригатьне хәреф буенча аңлаудан туган бу караш Шиһаб хәзрәтнең һөҗүмнәре астында юкка чыга. Ләкин асыл нокта анда түгел: шул мөнәсәбәт белән, шул турыда үзенең фикерен әйтү, үзенә башка[ча] уйларга хакы барлыгын исбат итәр өчен, дамелла, төп мәсьәләгә керешмәстән, элек бик киң мөкаддимә язарга мәҗбүр булган. Ястү фарыздырмы, юктырмы? – Моның бу яки теге ягын исбат итү Мәрҗани өчен зур бер плюс була алмас иде, аның әсәренең асыл кыйммәте шул мәсьәлә мөнәсәбәте белән кергән мөкаддимәдә, намаз мәсьәләсенәчә булган әүвәлге алтмыш битендә. Мөкаддимәдәге фикерне берничә сүздә җыярга туры килсә: «Аллаһ азат [итеп] яраткан акылга богау салмагыз, мөэминнең фикере хөр, менә Корьән, менә

хәдис – шуларны өйрәнсен дә үзе аңлаганча ышансын һәм гамәл кылсын. Мин үземне һичкемнең фикер һәм мәзһәбенә[5] ияргергә мәҗбүрмен дип белмим... рәвешендә нәтиҗә ясарга мөмкин булыр иде.

Һәр татар баласы кебек, без дә иман шартын ахырына кадәр укыган, андагы «кәферме син, мөселманмы син»нәрне бик тырышлык белән ятлаганбыз. Анда: «Тәңрем – Аллаһ, пәйгамбәрем – Мөхәммәд галәйһиссәлам, динем – ислам, китабым – Корьән» кебек, диннең катгый нигезләре белән беррәттән үк, игътикадта мәзһәбем – «әһле сөннә вәл-җәмәга»[6], гамәлдә – Әбү Хәнифә, дип өйрәттеләр. Соңра игътикадта мәзһәп әшгари белән матүридигә аерылганын, гамәлдәге мәзһәбләр – хәнәфи, шафигый, малики, хәнбәли икән – ахирәт көнендә җәһәннәм утыннан котылуны теләүчеләр үзләренең бөтен игътикад һәм гамәлләрен шул алты кешенең икесенә тапшырылу мәҗбүрилеген, без әшгари белән хәнәфигә ияргәнебезне, аларга каршы барырга ярамавын белдерделәр. «Бисмилла», «Аллаһ», «Корьән» сүзләре белән янәшә өйрәтелгән ул «әшгари», «хәнәфи» сүзләре безгә, бер безгә генә түгел, һәр мөселман баласына җиде яшьтән керә башлап, мохитның тәэсир итә баруы белән алар йөрәкнең төбенә кадәр тамыр җәеп, бөтен акыл тормышын каплап ятканнар.

Моның белән дә тукталмаган, яшең арту, күбрәк аңлый һәм китаплар өйрәнә башлау белән синең игътикадың, бөтен галәм һәм яратылган нәрсәләрне берничә сүздә җыеп бирер мәртәбәдә, гади һәм катгый калыпка коелган була.

Дөнья җиде көн эчендә яратылган, аның гомере җиде мең еллар. Бу вакыт үтеп бара инде. Адәмнәр һәр сәгать кыямәтне көтәргә тиешләр. Тормышта яхшылык һәм изгелек исеменә ни нәрсә, нинди эш булырга мөмкин, аларның һәммәсе булып

---

[5] Мәзһәб – мөселманнар хокук системасына нигезләнгән дини юнәлеш.

[6] Әһле сөннә вәл-җәмәга – Сөннәт һәм бердәмлек тарафдарлары, ягъни пәйгамбәрнең өйрәтмәләренә берсүзсез иярүче сөнниләр.

үткән, киләчәк көндә алар булырга мөмкин түгел. Үткәндә изге сәләфләр бар, изге галимнәр бар. Алар диннең, дөньяның һәммә серен аңлап, безгә ачып киткәннәр. Безгә аларныкына бер хәреф арттырырга мөмкинлек юк, иске китапларда ни бар – без, мөселманлыгыбыз буенча, шуларны турыдан-тугры кабул итәргә тиешлебез. Дөньяның гомере аз, кыямәт якын, озакламый Яэҗүҗ-Мәэҗүҗ[7] чыгар, Бәни әсфар кавеме[8] дөньяны басып алыр, Дәҗҗал[9] адәмнәрне аздырыр, Дәббәтел-арз[10]: «Син – кәфер, бу – мөэмин» дип маңгайларга мөһер басып йөрер. Хакыйкый мөэмин дөнья кайгысын ташласын да ахирәте белән мәшгуль булсын. Ягъни дөнья турында яңа бер фикер булырга мөмкин түгел. Һәр яңа – бидгать һәм гөнаһ, һәр искелек мөкатдәс. Киләчәктә ни дә булса көтмә, «ислам чит-ят булып башланды, чит-ят булып бетәр», дигәннәр, мөселманнар дөнья йөзеннән хур һәм кадерсез рәвештә бетәргә юкка чыгарга тиеш. Башка юк. Яэҗүҗ, Дәҗҗал, кыямәт.

Балигъ булып, дөньяга үз күзе белән карый башларга тиеш бервакытта ислам угылларының фикри тормышлары менә шундый игътикад, шундый авыр ташлар белән бастырылган, аның фикере шундый богаулар белән богауланып, мәңгелек таш зинданга бикләнгән иде. Ул югары[да]гы игътикад хакмы-дөресме, ул исламның рухына муафыйкмы – анысы безнең мәсьәләбезгә керми. Асыл әһәмият – бөтен мөселманнарның рухани тормышы шундый таш диварлар эченә бикләнгән булуы – һәр яшь егет шуның эчендә багланып калу ноктасы.

Дөньяда яши торган, яшәргә хакы булган кавемнәр тормышка якты карый, аларның акылында хөррият хис итеlә, киләчәккә карашларында өмет була, ягъни алар тормышның

[7] Яэҗүҗ-Мәэҗүҗ – ахырзаман алдыннан чыгачак гадәти булмаган халык.

[8] Бәни әсфар кавеме – ахырзаман алдыннан чыгачак гадәти булмаган халык.

[9] Дәҗҗал – ахырзаман алдыннан чыгачак гадәти булмаган бер зат.

[10] Дәббәтел-арз – ахырзаман алдыннан чыгачак гадәти булмаган бер хайван.

һәммә яхшылыгы артта димиләр, бәлки алгы көнгә якты өмет белән карап, көннән-көн үсә, күтәрелә баруга, кыскасы, үсешкә ышаналар. Безнең халыкта шул беткән иде, бөтен мөселман дөньясында «һәр искелек – мөкатдәс, һәр яңа – хәрам һәм көферлек» игътикады шул дәрәҗәдә нык хөкем сөрә иде ки, ислам тормышы шуның тәэсире белән, паралич сугып, мәңге кузгалмаска хөкем ителгән адәм кебек бер хәлдә иде. Бөтен ислам дөньясын каплап, бөтен табигатьне караңгы зиндан ясап, авыр таш булып басып яткан бу тимер катлау унтугызынчы гасырның яртыларына таба төрле җирдән чатный, ярыла башлады.

Кыю ирләр аның басуына чыдый алмый, җимереп өскә чыга башладылар. Курсави бездә бу ирләрнең беренчеләреннән. Ләкин аның мохитта тудырган тәэсире ким булды. Мәрҗанидә исә без инде горур бер каһарман күрәбез.

Аның бөтен әсәрләре – фикердә хөррият белән, киләчәккә якты кара белән, адәм акылына ихтирам белән сугарылган. Фикердә булсын, гамәлдә булсын, һәр искелек – мөкатдәс, һәр яңа – хәрам һәм көферлек» игътикады белән нинди дә булса бер прогресс, үсеш һәм хөррият рухының жыела алу ихтималы юк. Без дөньяга өмет белән карарга, киләчәктә яңадан терелергә теләсәк, безгә һәрнәрсәдән элек шул «сәләф» дигән, «мәзһәб» дигән нәрсәләрнең авторитетын бетерү тиешле иде.

Билгеле сүз белән әйтелсә, «ижтиһад беттеме, түгелме» мәсьәләсенең кире рәвештә хәл ителүе кирәк иде.

Шиһаб хәзрәттә, бигрәк тә «Назурә»дә без бу мәсьәләне киң рәвештә куелган[ын] табабыз. Сәләф ни дигән, борынгылар китапка ни язган – хәзерге мөселман шул сүзгә хәрефкә хәреф буйсынырга тиешле иде икән – Шиһаб хәзрәт килде дә: «Юк, бер дә алай түгел! Мөэминнең акылына богау салмагыз, Аллаһ Тәгалә бөтен өстенлекне әүвәлгеләргә биреп, безне бөтенләй мәхрүм [итеп] яратмаган, ижтиһад капкалары иясе булган һәр мөэмингә ачык, рәхим итеп керсеннәр дә, үзләренең акылы, фикере хак дип аңлаганча алсыннар», – диде.

Мондый сүзне бер Мәликов, бер Гаспринский әйтсә, тәэсире булмас иде. Чөнки ул кәферләр эчендә – Франциядәме, кайда – укыган. Үзе тар чалбар кия, тәмәке тарта – андый күңеле каралган морзалар ни сөйләмәс.

Ләкин Мәрҗани башка: яхшы атаның баласы, Бохара шәрифтә ун ел укыган, Казанның беренче мөдәррисе, үзе шул Тәфтазани һәм Нәсәфиләрдән артык гарәпчә яза – бу инде кемне дә уйга калдырмаслык түгел.

Безнең игътикадыбызда хәзерге адәмнәрнең һичберсе Корьән-хәдисие аңлый алмый һәм аңа мәгънә бирергә ярамый да иде. Мәрҗани килде дә сәләфләр әйткән сүзгә канәгатьләнмичә, хәтта борынгы китапларның сүзенә каршы барып, Коръәнне, хәдисне үзе аңлаганча тәфсир итә башлады.

Кызык бер игьтикад – ләкин хакыйкать шулай бар иде – ул вакыт[та]: «Коръәнгә мәгънә бирсәң, кәфер буласың», – диләр иде. Коръәнне көйләп укыйлар, ләкин мәгънәсенә якын бара алмыйлар, бу сәләфләрнең привилегиясе, хәзерге адәмнәр өчен ул турыда сөйләү гөнаһ иде. Мәрҗани шуны гамәле белән жимерде, Коръәнне үз акылы белән аңлап, хөкемнәр ала башлады – ул иҗтиһад[11] капкасын ачты, башкалар курыкмасын, башкалар да бу капкадан керсен өчен, галимнәрнең үзе канәгать булырга тиеш авторитетларын ярдәмгә чакырды. Ислам әсәрләрен өйрәнүчеләргә мөхтәрәм исемнәре мәгълүм булган күп галимнәрнең иҗтиһад бетмәү һәм акылга хөррият бирү турындагы сүзләрен китерә, болар арасында ул заманның туң акыллыларын, һәр турыда «сәләф» дип, «мәзһәб» дип, «борынгы галимнең сүзе» дип торган әсир җаннарын дәһшәткә төшерер мәртәбәдә сүзләр бар иде.

Мәсәлән, Ибне әл-Гыйззенең «Мөшкилят», «Һидая»гә биргән искәртүеннән: «Мән йәтәгассабү би-вәәхиди мүгыыйнин гайрир-расүүли галәйһис-сәләәм [...]», – дигән кебек риваять-

[11] Иҗтиһад – нинди дә булса дини мәсьәләдә, Коръән һәм хәдисләргә таянып, үзлегеңнән нәтиҗә чыгару.

ләре ул заманның игътикады карамагында иманлы адәм теле сөйләргә батырчылык итүе мөшкел саналган сүзләрдән иде.

Әсәр баштан-аяк – шул, адәмнең акылы өстенә салынган богауларны өзү, фикернең искеләргә кол булып калуына каршы көрәшүдән гыйбарәт.

Таң алдыннан чулпан күренә, чулпан белән бервакытта җир йөзе тагын ныграк караңгылана. Мәрҗани – безнең таңыбызның чулпаны.

Бу – матур сүз түгел. Мәрҗани безнең фикри үсеш тарихында нинди тәэсир итүче икәнен бөтен куәте, бөтен ачысы белән тик безнең шикелле егерме яшьләргә кадәр акыллары бөтен ислам дөньясын каплаган туң һәм кара фанатизм астына ябылып, фикерләре сәләф сүзләре белән богауланып яткан, соңра азат ителгән, шул азат ителү юлында бик авыр дулкынланулар кичергән егетләр генә хис итә алачаклардыр. Рәшид Казыйның «Чулпан» һәм «Миръат»лары, Исмәгыйль бәкнең «Тәрҗеман»нары – болар безгә ул вакыт[та] вак, чүп-чар нәрсәләр иде. Алар аркылы без Европаның шәплеген, мөселманнарның бетеп барганын белсәк тә, бу фактта аларга кушылсак та, бу факттан туачак нәтиҗәдә алардан аерыла идек. Борынгы китаплар ислам һәм мөселманның хур һәм кадерсез булып бетүен хәбәр бирә. Бәс, анда нindидер прогресс, мәдәният гаугаларына мәйдан калмаган. Үзенең алган юлында ныклыгы, фанатизмы чиктән тыш куәтле булган шәкерт, мантыйкчы, беләм дип дәгъва итүче егетләргә тәэсир итә алудан «Тәрҗеман»нар, «Чулпан»нар гаҗиз иде. Ул беләм дип дәгъва итүче һәм фанатикларны үзләре утырган позициядән чыгарырга, иң элек шул үзләре дә ышанырга тиешле ислам галимнәренең сүзләре ярдәме белән аларның башындагы фанатизмны куып чыгарырга кирәк иде. «Назурә»ләр менә шул хезмәтне үтәде. Моның теле «Габделхәким», «Казый мөбарәк» шикелле авыр стильле әсәрләрне укый алуны һөнәргә санаган кадими егетләр дә хурланмый укырлык дәрәҗәдә авыр, кыска, кискен иде. Бөтен тәртибе, бөтен бәян рәвешләре дә шул укыган шәрех һәм хашиялəрнекенә – моңарчы

укып ләззәтләнеп килгән нәрсәләргә охшый – хасил [булган] Шиһаб хәзрәт – кадими мәдрәсә крепостенә кием алыштырып кергән дошман гаскәре. Ул тышы белән безнекенә охшый, шуңа күрә аны эчләренә алалар, укыйлар, ләкин укудан калган тәэсир бөтенләй башка.

Ислам дөньясын каплап яткан караңгы фанатизм йөрәкләрендә тирән тамыр җәйгән, ләкин табигате белән булдыклы булган затлар ул тамырларны суырып ташлап, дөнья һәм тормышка үз акыллары, үз фикерләре белән карар мәртәбәдә хөррият алу өчен яңалык тарафыннан бик куәтле һөҗүмнәргә мохтаҗ иде. Шиһаб хәзрәт шул һөҗүмчеләрнең куәтлесе булды. Чит кыяфәттәге дошманны күрү белән таныйсың да якын китермисең. Ләкин Шиһаб хәзрәт безнең үз киемебездә килде. Ул безнең йөрәк серләребезне, барлык позицияләребезне белә иде, шуңа күрә фанатизм эченнән акыл һәм фикерләрне коткару, җаннарыбызны хөрриятькә чыгаруда без, мәдрәсә кешеләре, өчен Шиһаб хәзрәт иң куәтле тәэсир итүчеләрдән берсе булды.

## II. «Мөстәфадел-әхбар»лар

«Назурәтел-хак»ның кыйммәте тарихи. Ул безнең фикри үсешебезнең бер баскычында куәтле тәэсир итүче булды. Ул безнең фикердәге инкыйлабыбызның бер дәверендә йөрәкләребездә эз калдырды – без аны шул үткәндәге тәэсире өчен изге исем белән телгә алабыз, шуның өчен иясенә Тәңредән бөек рәхмәт сорыйбыз. Әмма «Мөстәфадел-әхбар»ларга килгәндә, боларның әһәмияте үткәндәге хезмәтләре өчен генә түгел, болар бүген дә һәм киләчәктә дә үзләренең кыйммәтләрен югалтмаячаклар, чөнки болар безнең милли тарихыбызның, бердән, аталары, икенчедән, нигезләре. Әсәрнең үзенә туры барып керсәк, яраклырак булыр.

«Мөстәфадел-әхбар» – җиде йөз сәхифәгә якын ике томлы тарихи әсәр. Бездә элек пәйгамбәрләр тарихы һәм ислам тарихлары бар иде. Бик сирәк кулларда Әбел-Гази да очраш-

тыргалый иде. Ниндидер бер уйдырма – «Тәварихел-Болгар» дигән урам әкияте – йөри иде. «Мөстәфадел-әхбар» тарихын оныткан, үткәненнән тәэсирләнгән булуны күңеленнән чыгарган без, татарларга, көтелмәгән бер искәртү, бер хезмәт булды. Төп тема итеп татарлар алынган бу китап үзенең эченә керәчәк вакыйгаларны тирән бер сызык белән икегә аера: 1) безнең халкыбызның рус кулы астына кергәнгә кадәрле булган тормышы, ягъни бәйсезлек дәвере; 2) русның хөкем ителүенә төшкән хәлдән соңгы заманнар, ягъни хөкем ителү дәвере.

Тормыштагы шул аерылуга каратып, әсәрдә ике бүлек ясалган. Беренчедә безнең үткәннең мөстәкыйль көннәре, икенчедә хөкем ителгән заманнарыбыз, Шиһаб хәзрәтнен үз гасырына чаклы.

Әсәрнең телен хәзерге замандагы стиль белән чагыштырып торуны кирәк тапмыйм. Шиһаб хәзрәт әсәрендәге җөмләләрнең шома булмавына, анда бик күп гарәпчә һәм фарсы сүзләр керүенә гаҗәпләнергә түгел, бәлки татарча китапны уку наданлык саналган һәм аталары, хатны гарәпчә яза белмәгән өчен, мәдрәсәдәге угылларын сүгә торган ул дәвердә үзенең күп хезмәт кергән әсәрен һәркем тарафыннан хурланган татар теле белән язарга батырчылык итүе өчен Мәрҗанинең бу эшенә хәйран булырга тиешлебез.

Йосыф Акчура әфәнде үзенең «Голүм вә тарих» дигән әсәрендә Шиһаб хәзрәтнең «Мөстәфад»е белән Риза казыйның «Асар»ын милли тарихыбызның нигезләреннән саный.

Әсәрне ачып, укый башласак, без бу сүзнең мәгънәсен ачык аңлаячакбыз. Әсәрнең тышкы киеме чибәр түгел, андагы материал да Европа галимнәренең әсәрләрендәгечә ачык һәм табигый тәртип белән тезелеп язылмаган. Ләкин ул вакытта безнең артык бер нәрсә көтәргә хакыбыз да юк иде. Киләчәк көннең тарихчылары «Мөстәфад»ның шәкел ягыннан булган кимчелеген күрмәячәк, теленең тарлыгын да сизмәячәк. Ул иҗат куәте шул дәрәҗәдә сындырылган, капланган бер халык эченнән «Мөстәфад»тагы кебек бер хакыйкать эзләүче, сүз һәм

риваятьләргә ышанмыйча, атын җигеп, мокшы авылларына барып, карт мокшылардан материал җыеп йөрүче, әллә кайдагы кабер ташларын казып йөрүче бер адәмнең чыгуына, чыннан да, гаҗәпләнәчәк. Чөнки «эш – кирәккә, сорауга җавап булып чыга», – диләр. «Мөстәфад» язылган заманда халыкта андый бернәрсәне сорау, аңлау кайда – аның өчен «мәҗнүн» дип сүгәләр генә иде. Ләкин даһи шуның белән даһи ки, ул заманыннан күп еллар алга китә. Ул заманының гомуми фикерләре белән хисаплашмый – аны тәкъдир итмиләрме, сүгәләрме – болар аны туктатмый, чөнки тормыш һәм табигатьнең эчке тәэсирләре белән туган иҗат куәте аңа тынычлык бирми, ул хәтта үзе бик ачык аңлап җитмәгән хәлдә рухының эченнән килгән тавышка колак сала, шул теләккә хезмәт итә.

Тарих язучыларны икегә аералар. Йосыф әфәнде боларны беренче кул, икенче кул дип атый. Беренче кул тарихчылар моңарчы тарих китапларына кермәгән хәл һәм вакыйгаларны иске һәйкәлләрдән, кабер ташларыннан, төрле кульязмалардан, халык авызларыннан алып җыялар, тарихка кертәләр. Ягъни материалны беренче кулдан алалар. Икенче кул тарихчылар төрле китапларда булган тарихи вакыйгаларны үзенчә төзи яки чит телдән үз теленә күчерә. Риза казыйның «Асар»ын беренче кулга кертәләр. Чөнки ул материалны үскән җиреннән үз кулы белән йолкый, аннан «Асар»ына кертеп, тарих сурәте бирә. Гайнетдин Әхмәрев, имам Халиди, Зәки Вәлиди, Һади Атласи – болар рус, гарәп яки башка халыкларның тарихи әсәрләреннән җыеп, безгә күчерүчеләр булганга, икенче кул тарихчылардан.

«Мөстәфадел-әхбар»ның икенче бүлеге баштанаяк беренче кул эше. Ул анда моңарчы һичбер тарих китабына кермәгән вакыйгалар һәм исемнәрне үз тырышлыгы белән тормыштан, хатлардан, кабер ташларыннан, сүзләрдән җыеп оештыра. Казан, Түнтәр, Мәчкәрә, Чистай, Курса, Ашыт – белмим, тагын әллә нинди авыл һәм шәһәрләрнең галимнәре һәм мөдәррисләре – болар һәммәсе Шиһаб хәзрәтнең арымас-талмас тырышлыгы белән тарихи материаллар эченә кереп киткәннәр.

«Мөстәфад»ның беренче бүлегенә килгәндә, монда беренче кул, икенче кул – һәр икесе гамәлдә. Һәр тарихчы кебек, Шиһаб хәзрәт тә, әлбәттә, язачак ввакыйгалары, ирләре хакында тулы мәгълүмат бирү өчен күп тарих китаплары актаргандыр. Ләкин аның даһи акылы боларга канәгать итмәгән. Ул китапны ташлап, тарихи бер хакыйкатьне эзләү өчен мокшы авылларына, әллә кайдагы ташландык каберләргә киткән, искедән зур нәселләрнең варисларында булган, борынгы китап читләрен, дәфтәр битләрен актарган.

Язучы халкыбызның тарихыннан хәбәрсезлеген, моның гайрәтләр сүнеп, хурлыкка калырга сәбәп булуын бәян иткәннән соң, тарихчының тарихи материалга ничек карарга тиешлеген сөйли дә үзенең максатын бу рәвешчә йомгак ясый:

«Без инде белә хәбәрдар булганыбыз хәтле, Болгар һәм Казан хәлләренә бәйләнешле хикәяләр, хәбәрләр, риваятьләр һәм сүзләрне кулыбызга төшкән кадәр китаплардан, язмалардан җыештырып, бу китапны төзибез. Чөнки тарихчының вазыйфасы – үзе хәбәрдар һәм игътибарга лаек сүзләрне, хәбәрләрне арттырмыйча, киметмичә, ничек бар шулай китерү, эчтәлегенең төп өлешен төшереп калдырмыйча һәм берәүнең файдасына яки икенченең зарарына тарафдар булмыйча аңлатып бирү. Булганны, яхшымы ул, яманмы, булганынча бәян итү».

Менә шул вакыйганы булганынча бәян итү өчен, Шиһаб хәзрәт кулына төшкән кадәр булган тарихи китапларны актарган өстенә искенең калган әсәрләрен, тарихи дәгъваларын исбат итүдә ярдәмгә чакыра.

Болгарлар хакында «төрек белән сәкалибә арасында туган бер халык» дигән мәшһүр сүз бар. Тарихчы шуның «төрек» дигән ягын ала да, иске заманда болгарлар хакында язган әсәрләрдәге күп болгар сүзен хәзерге халкыбызда таба. Моннан болгар белән безнең телдә берлегебез чыга. Шуның өчен ул зиратларга йөри. Спас өязендә Шәһре Болгардан алтмыш чакрым ераклыкта Иске Рәҗәп авылында «Ташбилге» исеме белән билгеле борынгы бер зират бар икән, тарихчы монда

булган. «Башка ташлары җимерелеп беткән, тик өчесе бар», – ди. Шул ташлардагы язуның берсе бик хуш, оста кеше язган нәсех язулы, икенчесе һәм өченчесе дә шулай ачык язган күфи язулы. Болар болгар заманыннан калган, дип уйлана. Үзләрендә «Әнбал углы Хөсәен», «рәҗәб аеның өченче көне ирде», «тарих йете йөз кырык бишенчедә» дигән кебек, беренчедән, кай заманда язылганын, димәк, кайсы халыкныкы икәнен күрсәтә; икенчедән, безнең хәзерге телебезнең үзе төзелгәндә төрле булган сүзләр бар – бу фактта безнең өчен асыл әһәмият татар мулласының тарихи хакыйкатьне эзләүдә шул мәртәбәгә җитүе, шулай нечкәләве. Болгарларның төреклекләре турында күп эзләнгән, байтак кабер ташлары актарганнан соң, «сәкалибә» мәсьәләсенә килә.

Кайберәүләр, «сәкалибә»дән славянны аңлыйлар икән, Мәрҗани боларны кире кага, үз тарафыннан «сәкалибә»дән максат – чуаш, чирмеш, ар кебек фин төркемнәре, ди. Шул дәгъваны исбат [итү] юлында тарих китапларындагы вакыйгалардан үзенә яраклы нәтиҗә чыгарырга тырышканнан соң, ул тагын ялганлау ихтималы булмаган үлек материаллар эченә, ул халыкның хәзергәчә дәвам иткән кайбер калдыклары арасына керә.

Хәзер дә Шәһре Болгар һәм Казан тарафларының төньягында – чирмеш һәм ар, көнбатышында чуаш һәм мокшы төркемнәре, көнчыгышында – башкортлар. Бу Казан тарафларында һәм әүвәлдә финнардан бер төркем, соңра алар китеп, я мөселман булган я аралаш утырган һәм чирмеш теленчә, я чуаш һәм ар теленчә аталган авыллар бар: мәсәлән, Шинбер, Киме һәм Күәм исемендә мөселман авыллары бар. Чирмешчә мәгънәләре: кара кан, итек, зират; «Ачасыр» чуаш теленчә «угылсыз» мәгънәләрендә була. Чирмеш иле, һәм Чуаш иле, Чуашлар орысы, Мажар, Бортас, Ар, Күшәр, Мокшы, Мокшы күл исемле авыллар бар. Мамыш исемле авыл, асылда, бер Мәмеш исемле чирмеш исеме белән аталган. Кайбер фин авыллары мөселманнар теле белән аталган: мәсәлән, Сары Кукшай ягында Мирзалар исемле чирмеш авылы бар. Бу мок-

шы авылы Күшәр кешеләренә һәм башкаларга кол булып, бу заманга якын сатыла һәм сатып алына иделәр... Шуңа караган кызык бер документны Шиһаб хәзрәт Казан сәүдәгәрләреннән Исмәгыйль Апанаевтан калган язу дип, «Мөстәфад»ка кертә: «Тарих мең дә йете йөздә сиксән сигезенче елда январьның сигезенче көнендә Казанның иске бистәсенең йомышлы кеше мин, Йосыфф Динмөхәммәд улы, саттым үземнең өлешемә тигән колымны Казанның иске бистәсенең Исмәгыйль Апанай Хафиз улына йөз сум хак белән, бу искә алынган колларым Алат юлында Арча округында Күшәр илендә йорт белән торучылар. Искә алынган колларым: әүвәл Бикбай Сәедкәй улы, хатыны Нәсыйхә, бер сабый кызы белән бер улы Бикчәнтәй Бикбау улыны, икенче колымның улы Мортаза Мөэмин улыны һәм шулай ук шул Күшәр илендә биләп торган җирләрем һәм печәнлегем – барчасы Исмәгыйль агайга».

Гомумән, әсәрдә куәтле иҗат сәләте ялтырап бара. Дини фикер һәм игътикад турында «сәләф» дип, «мәзһәб» һәм «риваять» дип акылын богауларга риза булмаган бу бөек тикшерүчене без монда да җиңел таныйбыз. Ләкин ике юлда ике төрле эз кала: дини мәсьәләләрдә Шиһаб хәзрәт – ватучы, җимерүче. Аның табигый рәвештә хөр яратылган куәтле акылы үзеннән элеккеләр тарафыннан ясалып калдырылган тар рамкаларга сыймый, ул аларны ватып чыга. Тарих бабында исә ул – ватучы, җимерүче түгел, бәлки яңаны ясаучы, үзенә кадәр булмаган нәрсәне тудыручы, китаплар сәхифәсендә таркау яткан материалны бергә оештырып, аның өстенә карт мокшылар сүзен, иске дәфтәрләрдәге, туфрак астында калган кабер ташларындагы язуларны җыеп, милли тарихка нигез салучы, тагын кыскасы – тарихыбызның иҗат итүчесе.

*«Аң» журналы. – 1915. – № 1. – Б. 7–19.*

# *Галимҗан Ибраһимов*

## Бөек остазыбызның тарихи бер тәнкыйте

Гоголь сүзе белән әйтсәк, һәр халыкта ике тип мөхәррирләр була:

1. Берсе үзенең күңелендәге уен боргаламый, буямый, туптуры әйтә. Ул тормыштагы бер нәрсәдән әсәрләнгән. Бер нәрсәне хата яки зарарлы таба, җәмәгать файдасы өчен ул хатаны, ул зарарны бетерергә яки үзгәртергә тиеш [дип] күрә, шуннан соң, тота да бер мәкалә һәм бер әсәр язып, шуңа каршы сугыш ача.

Аның фикеренә халык ничек карар – ул моны уйламый. Хәтта сүгәрләр, гаепләрләр дип тә белә, ләкин һаман язмый кала алмый. Заманнарындагы гомуми фикерләргә капма-каршы рухта булган «Миръат»лары белән Рәшид казый һәм «Шәкерт һәм студент»ы белән Фатих Кәрими әфәнделәр башлап мәйданга чыгышларында шул тип мөхәррирләрдән иделәр.

2. Икенче типларны берәү, агулы сүз белән, хамелеоннар дип атый. Шундый бер мәхлук бар икән, нинди җиргә барса, ул шуның төсенә керә: туфракта карала, комда саргая, яшел яфраклар эчендә яшелләнә.

Бер вакыт шәп ысул җәдидә көрәшчесе булу; 1905 елда социалист булып, милләт сүгү; мохиттә ул төс беткәч, үзең милләтне куәтләү – менә бу шул хамелеон дип аталырга тиешле икенче типларның эше. Бу ике типны табигатьнең биреше ягыннан итеп ачарга кирәк булса, шулай аерырга мөмкин.

Беренче тип язучыларның йөрәгендә табигать тарафыннан салынып, тормыш белән тәрбия кылынып килгән илаһи бер орлык була. Аларның бөтен язулары, бөтен хәрәкәтләре, мәсләк һәм фикерләре – шул орлыкның җир өстенә чыгып, үсүеннән гыйбарәт. Әрем орлыгыннан гөл тууын яки, киресенчә, көтү мөмкин булмаган кебек, табигать һәм тормышлары белән билгеле бер юл белән барырга әзерләнгән бу тип язучылар да шул үзләренең тоткан мәсләгеннән башкага борыла алмыйлар. Алар теләсә-теләмәсә дә шуңа мәҗбүрләр. Ул кызыл гөл булып үсәргә яратылган, әмма халык ал чәчәк кенә сөя, бәс, аны яратмаулары, аңа игътибар итмәүләре бик мөмкин, ләкин ул мохитнең фикеренә, теләвенә карап, үзен үзгәртә алмый.

Нинди орлык – шундый чәчәк.

Ләкин халыкның зәвыгы – вакытлы нәрсә. Ул тиз үзгәрүчән. Бу биш-ун елда ал чәчәк яратып, кызылны игътибарсыз калдырган икән – бик мөмкин бераздан соң, аның зәвыгы, карашы алмашынып, ал чәчәкне ташлар да элек игътибарсыз калдырган кызыл гөлне ярата башлар. Әмма икенче типлар табигать тарафыннан алай билгеле бер нәрсәгә әзерләнгән булмыйлар. Алар ачык төстә буш пыяла савытлар. Ул савытның эченә нинди су салынса, алар шуның төсенә керәләр. Мондый буш пыяла савытка су салучы исә – аның эчендә яшәгән мохите, халкың модасы.

Мохитнең хәзерге фикерендә иң куәтле төсе ысул җәдидә икән – савытка шул су тула да ул ысул җәдидә каһарманы булып мәйданга чыга, тирә-ягына прогрессив җәдид фикерләре чәчрәтә башлый – әсәрләре шул рухта чыга. Аннан соң мохит үзгәреп, тирә-якны кызыллык баса, иң куәтле төс кызыл суллык була икән – һәрвакыт мохитнең фикере белән генә тула торган буш пыяла савыт кызыл төскә керә, чөнки аның эченә мохиттән агып, кызыл су тулган була, ул тирә ягына, әсәрләре аркылы, кызыл су-суллык чәчрәтә башлый. Тагы бер вакыт килсен дә суллык, кызыллык модадан чыгып, тар милләтчелекме, хәтта динчелекме мәйдан алсын – пыяладагы су да үзгәрә. Аннан

милләт төсе белән буялган тамчылар чәчри башлый. Гомумән, аның үзенең бер төбе, бер төсе булмый – эчендә яшәгән мохиттә нинди су булса, пыялада шул тула, табигый шул төстә булып күренә.

Болар халыкка, шөбһәсез, ярыйлар да. Боларның араларында ихласлылары була, алар, бичаралар, чын күңелдән һәрбер яңа төскә кергән саен: «Менә хаклык кайда икән, без элгәре ялгышканбыз...», – диләр. Әмма арада үзенең төсен юри үзгәртүчеләр – халыкның зәвыгына ошаган нәрсә язып, юри шул халыкта мода булган төскә керүчеләр – халык яраткан масканы кирәк саен алмаштырып кия барганнары да була. Болар һәрнәрсәдән элек язган нәрсәләренең халыкка ошавы ягын карыйлар. Ни нәрсә хакында, нинди төстә язганда хуш күренүгә чыгуын алдан билгеләп, язуларына юри шул төсне бирәләр. Шуңа күрә, мохиттә җәдидлек өчен көрәшү яхшылык саналганда, болар прогрессив җәдид була, түбән халык, эшче һәм хөррият рухы мәйдан алса, болар шул рухны куәтли, тагы бер вакыт милләт дәвере керсә, үзләре ике-өч ел элек кенә кабәхәтләп сүккән милләтне изге бер нәрсә итеп мәйданга чыгалар, үзләрен шуның төсенә буйыйлар.

Шиһаб хәзрәт үзенең бөтен эше, бөтен язулары һәм бөтен тормышы белән әүвәлге тип мөхәррирләр җөмләсеннән. Аның бөтен рухани тормышы – эчендә яшәгән җәмәгатьнең зәвык һәм фикеренә каршы. Ул бөтен голяманы хата юлда таба. Моны язса, сөйләсә, аны, табигый, яратмаячаклар, сүгәчәкләр, җәһәннәмгә җибәрәчәкләр, ләкин ул моңа төкерми дә. Үзенең ни нәрсәне хак дип ышангансың, төп игътикадың[1] белән нинди фикерне хакыйкать дип табасың – аныңча, шуны үзең ышанганча язарга тиешле. Халык яратмый, сүгә, мең төрле гөнаһларда гаеплләп, сине хур итәргә тырыша, дөньяда булдыра алмаса, динеңә, вөҗданыңа чабаталы аягы белән кереп, сине җәһәннәмгә җибәрә икән – барысын, теләгәнен кылсын, ике ти-

[1] Игътикад – дини ышану системасы.

енлек әһәмияте юк. Үзе чын дип ышандымы, ул халыкның ничек каравын һич игътибарга алмый – шуны сөйли, яза һәм эшли. Халыкның мондый һөҗүм гаепләүләренә каршы ул бер дә канын бозмый, аның бик табигый эш икәнен аңлый, аңа бер дә исе китми: «Сүзең дөрес, игътикадың сәламәт, карашың туры булганнан соң, наданнар һәм юләрләр, ахмаклар һәм киреләр өрсәләр, өрә бирсеннәр. Аллаһка тапшырдык. (Андый гаепләүләр дөньяда яңа эш түгел). Алар Аллаһ Тәгалә хакында: «Аллаһ үзенә бала алды», – диделәр, Аллаһның китабы булган Коръән хакында: «Әүвәлге кешеләр әкиятләре», – диделәр, пәйгамбәрләрнең олугы Мөхәммәд галәйһиссәлам хакында: «Чынлыкта, ул – юләр», – диделәр, ди. Заманындагы халыкның өрүенә ул, чыннан да, бер дә игътибар итмәде, аны аңламадылар, урыныннан чыгардылар, мең төрле гаеп һәм яла яктылар, чабаталы аяклары белән аның саф вөҗданын таптап, аны мөгътәзилә[2] һәм кяфер ясадылар – җәһәннәмгә хөкем иттеләр. Ул һаман үз юлында, үзенең ялгызлыгы белән горур бер хәлдә дәвам итте. Ныклыкның бу дәрәҗәсе төрки-татар галәмендә тик мәрхүм Исмәгыйль бәк Гаспринскийда гына күренгән.

---

Шиһаб хәзрәт, Бохарадан кайтып, Казанның беренче мәхәлләсенә имамлыкка чакырылгач, махсус голәма мәҗлесе ясап, аны имтихан кылырга булалар. Үзен бөек дип ышанганнардан берсе: «Синнән сүз сорамакчы була идек», – ди.

Олуглар тарафыннан, яшьләрнең чамасын таратып карау өчен, бу рәвешле «сүз сораулар» ул заманда бөтен ислам дөньясының гыйльми гадәтләреннән иде. Табигый, моңа каршы барырга һичкемнең батырлыгы җитми иде. Ләкин Мәрҗани шундый кечкенә урында да үз табигатеннән читкә чыга алмый. Үзенең имамлыкка ярау-ярамавы мәсьәләсенә тәэсир итү мөм-

[2] Мөгътәзилә – исламда барлыкка килгән бер секта әһеле.

кин булырдай – димәк, башкалар каршында иң зур мәртәбәдән мәхрүм калу булып чыгуы ихтималлы бер турыда да – мәгънәсез гадәткә сукырларча иярүне аның җаны кабул итми: «Ник миннән сорыйсыз? Мөшкел мәсьәләгез булса, мәҗлестә зур голямалар бар, алардан сорагыз», – ди.

Мәхәлләнең зур байлары, гадәттә, бик үзсүзле халык була. Алар шәкерт һәм хәлфәнең түгел, имам һәм мөдәрриснең дә һәр турыда үзенә кол булуын тели. Бөтен татарда ул шулай бара да: мәчет, мәдрәсә тирәсендә мәхәллә баеның сүзе канун [итеп] тотыла. Һәммә кеше моңа гади дип, шулай тиеш инде ул, дип карый; ләкин Мәрҗани моңа да буйсынмый. Бернәрсә аңламаган, тик акчасына алданып, белмәгән мәсьәләләренә тыгылган байларны, бик күп лыгырдый башласалар, башка чара булмагач: «Кит, ахмак, син нәрсә аңлыйсың», – дип, таяклап чыгарудан да тартынмый.

Сәмәрканд китапханәләреннән берсендә тирегә куфи язуы белән язылган бер Коръән саклана икән. Бу шәһәр рус гаскәре тарафыннан алынгач, моны Петербургка күчергәннәр. Җирле мөселманнар да, алган руслар да моны хәзрәти Госманның мосхәфе диләр иде. Хәтта аның кылыч белән шәһит ителгән вакытта Коръән өстенә тамган каны да бар. Бәс, шөбһәләнергә юл юк, һич тикшерми-нитми, моны шулай дип, бар да кабул итәләр. Ләкин Мәрҗанинең тирән карашы халыкның бу игътикадындагы хатаны күрә һәм аның Госман мосхәфе түгеллеген исбат итә. Мондый хәлләр – аның бөтен гомере буена чәчелгән вак кисәкләр. Ләкин шул кисәкләрдән权 бербөтен җыела.

Мин монда юри тышкы караштa бик очраклы һәм бик әһәмиятсез күренерлек җирләрен алам. Ләкин боларның һичберсе аның тормышына нисбәттә очраклы эш түгел, болар – аның бөтен мохиткә башка рәвештә яратылган табигатенең төрле сурәттә дөньяга чыгышлары. Болар безгә аны ачалар, ул бөек акыл һичбер турыда үзенең тиеш дип тапкан сүзен әйтүдән тыелмаганын, аның тирән карашы, иң гади нәрсәләрдән алып, иң зур мәсьәләләргә кадәр һичбер эшне, һичбер гамәл һәм фи-

керне үзенең үткен тикшерүеннән башка кабул итмәвен күрсәтәләр.

---

Шул баклардан үтеп, югары менә башласак, без аның бөтен ислам галәмен каплап туңдырган, кәлям, ышану һәм иҗтиһад[3] мәсьәләләренә, аның бу хакта бөтен дөньясына бер ялгызы диярлек каршы барып, заманына күрә, ни дәрәҗәдә оригинал һәм ни дәрәҗәдә хөр фикерләрне мәйданга куюына, бу хакта, бөтен мохиткә, бөтен голяма төркеменә каршы ялгызы көрәшкә чыгуына, гомумән, аның һәр турыда акыл хөррияте өчен бөтен ислам дөньясына каршы сугыш ачуы кебек, безнең фикри үсешебез тарихында тирән эз калдырган тырышуларына барып җитәргә тиешле булачакбыз. Болар инде язылып үтте. Мин бу мәкаләмдә Шиһаб хәзрәт өчен бик характерный булган бер әсәрне – аның тарихи бер китап хакындагы тәнкыйтен кыскача сөйләргә уйлыйм.

---

Бөек остазның ул характерный тәнкыйте – элеккеләр арасында бик зур шөһрәт һәм ышаныч казанган «Тәварихелболгария» дигән әсәр хакында.

Мәрҗани өчен бу тарихка каршы ачы тәнкыйть язу ни дәрәҗәдә табигый икәнен ачык аңлар өчен без элгәре бу әсәрнең эченә кереп, аның нидән гыйбарәт икәне белән бераз булса да танышырга тиешлебез... Китап «Рисаләи тәварихи болгария вә зикри мәүляна хәзрәти Аксак Тимер вә хараби шәһри Болгар» дип атала. Исеменнән дә аңлашылганга күрә, бу әсәр безнең бабаларыбыз болгарларның Аксак Тимер тарафыннан харап ителүе хакында.

---

[3] Иҗтиһад – нинди дә булса дини мәсьәләдә, Коръән һәм хәдисләргә таянып, үзлегеңнән нәтиҗә чыгару.

Атага хөрмәтсез балалар булырга мөмкин. Үз халкына каршы төрле мөгамәләләр мөмкин. Ләкин үзен Хисаметдин бине Шәрәфетдин Болгари дип атаган бу язучының үз бабалары булган болгарлар хакында бу дәрәҗәдә хөрмәтсез бер тойгы да булуы һәм аларның тарихи бәхетсезлекләре хакында бу дәрәҗәдә кара игътикад саклап, аны дөньяга язып чыгаруы – бу безнең кебек тик үзенең кавеме вөҗданын югалткан бер халык кешеләре тарафыннан гына мөмкин. Ул әйтә:

«Әл-кыйсса. Безнең Болгар әһеле дә бозыклык һәм баш күтәрү белән мәшһүр иделәр. Голямалары шәригатьтә хәйлә белән рибаның дөреслегенә фәтва биргәннәр иде һәм башка зина кебек, кеше үтерү кебек эшләр күп иде... Җомгадан калдылар, биш вакыт [намаз] артыннан укый торган догаларны калдырдылар, сыра һәм аның кебек нәрсә хәләл дип фәтва бирделәр, Мисыр[4] юк дип җомга намазын куйдылар. Имам Шафигый сүзе түгел дип аны сүктеләр. Гаед намазын куйдылар, Аллаһ Тәгаләгә гөнаһлы булдылар. Аллаһ Тәгалә шуның өчен Аксак Тимер хәзрәтне хакимлек итүче итте. Ул заманда Болгарда Бикчура хан иде, әмир Тимер хәзрәти Бикчура ханга илче җибәрде: ни өчен җомга һәм гаед [намазлары] укымыйсыз. Хан голямаларына әйтте: «Әмир Тимергә ни җавап бирерсез?» – дип. Голямалар әйттеләр: «Китаплар белән җавап бирербез», – диделәр. Болгар голямалары җавап бирделәр...».

Шундый гөнаһлары өчен Аллаһ Тәгалә Шәһре Болгар өстенә Тимерне җибәргән. Тимер голяманың җавабын ишетеп, гаскәренә әмер итте: «Укларыгызны һәм тупларыгызны атыгыз! Билләһил-галиййил-газыйм [Бөек һәм Олуг Аллаһ белән ант итәм], бу Болгар шәһәренең урынын юк итәрбез һәм харап итәрбез», – дип ант эчте. Өч көн эчендә шәһәребезне юк итте һәм харап итте. Таш кальгаларыбызны туп белән ваттырып, Волга төбенә салды. Вәзирләрне кистерде, энҗедәй кызларын һәм хатыннарын, кол итеп, гаскәр рәисләренә бирде, халыкны

[4] Мисыр – җомга намазын кайдадыр укыр өчен шәһәр булу шарты.

бер җомгадан [атнадан] таралып бетәргә әмер итте, голяманы таганга астырды һ.б.

Шулай итеп, бабалар-болгарлар үзләренең явызлыклары өчен Аллаһ Тәгалә тарафыннан җибәрелгән Аксак Тимер һөҗүме белән харап ителә, бу Тимерне язучы «мәүляна» [«хуҗабыз»] дип атый. Гомумән, бу фаҗигада аның болгарлык вөҗданы бик аз гына да селкенми.

Әсәр очраклы яки чыгарма рәвештә килеп чыккан бер нәрсә түгел. Ул заманындагы рухны бик ачык күрсәтә. Бу әсәр үз заманындагы ялгыш уйлар һәм хорафат белән ни дәрәҗәдә сугарылганлыгын түбәндәге мисаллар тагы ачалар. Ул Болгар тарихы язмакчы булса да, аңа кереш рәвешендә еллар, көннәр һәм айлар өстенлеге хакында байтак сүз бар. Мәсәлән, көннәр хакында: «Җомга көне – бәхет, мескеннәр хаҗы, кушылу көне һәм никах көне. Чөнки Адәм галәйһиссәлам белән Хавва (Аллаһ аннан риза булсын), Бәлкыйс белән Сөләйман галәйһиссәлам, Йосыф галәйһиссәлам белән Зөләйха, Муса галәйһиссәлам белән Сафура, хәзрәти Мөхәммәд галәйһиссәлам белән Хәдичә, Гайшә (Аллаһ аннан риза булсын) җомга көн никах кылындылар. Адәм галәйһиссәлам дөньяга җомга көн килде һәм җомга көн оҗмахка керде, җомга көн оҗмахтан чыкты. Җомга көн алты тапкыр йөз мең адәмнәрне Аллаһ Тәгалә җәһәннәмнән азат итәр. Һәркем җомга көн тырнак киссә, малы күп була һәм гомере озын була.

Шимбә көн – мәкер һәм хәйлә көне, шомлы көн. Чөнки ул көн пәйгамбәрләрдән алты кешегә шомлык билгесе булды: берсе Салих, берсе Нух, берсе Муса, берсе Гайсә, берсе Мөхәммәд галәйһиссәлам. Ләкин бу көндә ау ауламак бәхетле. Һәркем шимбә көндә тырнак киссә, бармагы яралана».

Көннәрнең берсен «бәхетсезлек», берсен «бәхет» дип тасвирлап чыкканнан соң, айларга килә, гомуми рух анда да шул: «Шәгъбан аеның сүриялеләрдә һәм грекларда «гадел» иде. Гарәпчә исем куелуның сәбәбе будыр ки: гарәпнең бәни Тәмим исемле кабиләсендә бер падишаһ бар иде, исеме Нәүфәл бине

Вәрака иде. Гаять олуг падишаһ иде. Үзе фәлсәфә гыйлеменнән бик маһир иде. Заманында аннан да хикмәт һәм фәлсәфә фәннәреннән галимрәк кеше юк иде. Галәмнең борынгылыгын исбат иткән иде. Бер көн ул фәлсәфә шаһы сәфәргә китте. Килеп юллары Гарәбстан диңгезенә төште. Җөрҗан исемле кальгада гаскәре белән кунак булдылар. Җөрҗан шаһы аны сахрага ау ауларга алып чыкты. Ау аулаган вакытта, каршыда күзләренә бер биек тау күренде. Җөрҗан шаһы әйтте: «Әй, гарәпләр хуҗасы, хәзер шул тауның башына чыгыйк. Анда бер чишмә бар. Башы бер, унике бүлек булып агарлар, һәр бүлек сулары бер-берсеннән аерыладыр. Бер бүлеге бик суык, бер бүлеге эссе. Кай бүлектә сөт тәме бар, кай бүлектә гамбәр исе бар. Кай бүлеге кара төсле, кай бүлеге кызыл төсле. Кай бүлеге агулы, кай бүлеге су булып агар, кара таш булып туңар». Моны күреп, Нәүфәл бине Вәрака гаҗәпләнеп әйтте: «Әй, Җөрҗан шаһы бине Рөстәм бине Мәлгам, минем бүсер зәхмәтем бар, бу чишмәләрнең кайсы бүлегеннән эчәргә әмер итәрсең?». Җөрҗан шаһы әйтте: «Гамбәр исе килгән бүлегеннән эч», – диде. Чөнки гарәп шаһы эчте, шунда ук шифа тапты».

Болгар халкының ислам динен башлап кабул итүе шул түбәндәге рәвешчә тасвирлана: «Барач хан заманында тарих өч йөз туксан алтыда иде, Болгарга сәхабәләр килгән заманда өйләре биш йөз егерме иде, дигәннәр. Үзләре утка табыналар иделәр. Искә алынган сәхабәләр Болгарда күп авыруларны дәваладылар, һәркайсы шифа таптылар. Боларның исемнәре билгеле булды: «Гарәбстаннан табиблар килгән, Мөхәммәд дигән пәйгамбәрнең яраннары, ди. Әмма иманда, диндә һәм әдәптә тиңдәшләре юк», – дип. Кыскасы, беркөнне Айдар ханның кызы Туйбикәдә паралич зәхмәте пәйда булды. Ничек кенә дәвалап карасалар да, файдасы булмады. Айдар ханның Барач исемле вәзире бар иде, әйтте: «Әй, ханым, яшең озын булсын, безнең шәһәребезгә Гарәп йортыннан өч табиб килгән, табиблыкта тиңдәшләре юк. Әмма диннәре безнеке кебек түгел». Айдар хан әйтте: «Ул табибларны чакыр, килсеннәр,

кызым Туйбикәне дәваласыннар». Кыскасы, Барач вәзир барып чакырды. Ул гарәпләр ханның йортына килделәр, кызны күрделәр, әйттеләр: «Бу – паралич зәхмәте, моңа «хәдәнг» яфрагы белән себерке бәйләп, мунчада чабарга кирәк». Хан әйтте: «Ул «хәдәнг» нинди агач?» Сәхабәләрдән берсе төрки теленә бик оста иде, әйтте: «Ул каен агачы». Хан әйтте: «Ул агач бездә күп, бәйләгән себеркеләребез дә күп». Сәхабәләр әйттеләр: «Безгә яңа агачтан алган каен яфрагы кирәк». Хан әйтте: «Кыш көнендә аны кайдан табарга?» Кыскасы, хан әйтте: «Минем дөньяда күргәнем бу кыз балам иде, бүтән балам юк. Аны терелтсәгез, яңа каен агачыннан себерке бәйләсәгез, мин сезнең динегезне кабул итәрмен». Кыскасы, пәйгамбәребез галәйһиссәлам бу өч сәхабәгә өч нәрсә биргән иде: сездән могҗиза сорасалар, бу өч нәрсәдән ярдәм табарсыз, дип. Чалма – аны Габдрахман бине Зөбәергә биргән иде. Кара савыт – аны Зөбәер бине Җәгъдәгә биргән иде. Таяк – аны хәзрәти Тальхәгә биргән иде. Чалма, кара савыт, таяк. Болар ул кара савытны куеп, кара савытка таякны кадап куйдылар. Хәзрәти Габдрахман (Аллаһ аннан риза булсын) пәйгамбәребез биргән чалманы башына чолгап, ике рәкәгать намаз укыды, бу ике сәхабә «амин» диделәр. Ул таяктан озаеп, яшәреп, Аллаһ Тәгалә рөхсәте белән, Аллаһ рәсүле могҗизасы бәрәкәтендә, боларга бер олы ботаклы каен булды. Аннан себерке бәйләп, хан кызын мунчага җибәреп чаптырдылар. Шунда ук терелеп, хан сараена йөгереп кайтты һ.б.».

Шул могҗизаны күргәч, әүвәл Шаһи үзе, аннан соң вәзирләре, алар артыннан бөтен Болгар кавеме ислам динен кабул иткән булалар. Сәхабәләр өч ел калып, аларга мәчетләр сала, дин өйрәтә, намаз укыта, шул чалма һәм таяк белән җомгада хөтбә укый булганнар. Өч елда тәмам урынлашып җиткәч, кайтып киткәннәр һәм шул өч сәхабә бөтен тормышы ислам тарихы белән иң аз таныш адәмгә дә ачык билгеле булган мәшһүр Габдрахман бине Зөбәер, Тальхә һәм Зөбәер бине Җәгъдә булган булалар.

Хәзерге көннең урта мәктәп баласы да бу сәхабәләр белән Болгар халкының ислам динен кабул итүе вакыйгасын бергә йөртүгә, тарих белмәү, дип көләчәк кенә. Ләкин безнең элекке заманыбызда башка һәр нәрсә белән бергә үз тарихыбыз, дини тарихыбыз да шул дәрәҗәдә ташланган иде ки, безгә араларында, берничә йөз еллык кына түгел, мең ел заман булган ике вакыйганы бергә бутасалар да, ышаныр идек. Чөнки гади халыкның тарихыннан хәбәре шул кадәр иде. Бүген берәү чыкса да, «Тәварихы Болгар»ны кире кагып, аңа тәнкыйть язып маташса, юк хезмәт дип карарга кирәк булыр иде, ләкин Мәрҗани дәверен безнекенә охшатырга мөмкин түгел.

Яраткан әсәрләрең кайсылары? Шуларны әйт, аннан соң үзеңнең кем икәнеңне сөйләп бирермен, диләр. Чыннан да, кешенең яратып укыган китабы – аның фикри мәртәбәсенең үлчәве. Баштанаяк иң гади акылга да сыймаслык әкият, ялгыш уйлар һәм хорафат белән тулган «Тәварихел-Болгар» ул заманда, бәлки, татар телендә язылган әсәрләр эченнән голяма һәм мәдрәсә әһеле арасында иң шөһрәтлесе һәм иң игътибарлысы булгандыр. Шуннан аларның фикер һәм игътикадына ул әсәрдәге ялгыш уйлар, хорафат һәм әкиятнең бик яраганлыгы үзеннән үзе килеп чыга. Шуңа күрә Шиһаб хәзрәтнең ул әсәргә тәнкыйть язуы, Хисаметдин Мөслимине кире кагудан бигрәк, ул заманның бөтен гомуми фикерләрен тәнкыйтьләү булып чыга. Чөнки Мөслиминең «Тәварих»ындагы нәрсәләр аның берүзенеке түгел, бәлки бөтен татар дөньясының уртак малы шикелле. Ягъни ул ялгыз түгел, аның язганнарына мохит кул куя, мохит аны яратып, үзенеке [итеп] ясый. Тагы бер кабатлау: шулай булгач, Шиһаб хәзрәтнең ул әсәр хакындагы тәнкыйтен шул замандагы булган гомуми хорафатка, гомуми тарихи хатага каршы сугыш ачу, дип карарга кирәк.

Шиһаб хәзрәтнең табигатендә кызу полемик каны бар. Ул дискуссияләрендә дошманга куәтле һөҗүм белән ташлана. Аларга каршы кулланган сүзләрендә бер дә ачы булмасын, кәефләрен кырмасын, дип сакланып тормый: йөрәгендәге тәэсир нинди сүзне теләнә китерсә, каләме шуны яза. Гомумән, ул күп туры да, ачы, үткен, кискен каләмле. Әдәби һәм гыйльми дискуссияләрдән башка, «Мөстәфад»ның икенче томында голяманы сыйфатлауда ул бер дә ачы булыр, кәефләре кырылыр яки дошман булыр, үземә зарар итәрләр, дип тормый, шәхеснең анда тудырган тәэсире ни булса, шуны ачысы, зәһәре белән әйтә. Һәр турыда искелеккә табынып, гомуми фикерләргә кол булып йөргән фанатик голяма Шиһаб хәзрәтнең фикер һәм игътикад бабындагы хөрриятен яратмадылар. Ике арада зур дошманлык китте. Менә шул төркемнән кайберләрне ул «Мөстәфад»та ничек тасвирлый.

Халыкның «гасырының бердәнбере», «заманының бердәнбере», «заманының галиме», фәлән дип йөрткән һәркем тарафыннан татар мөдәррисләренең иң алдагыларыннан саналган Кышкар дамелла Исмәгыйль хакында әйтә: «Бер дәрәҗәдә зирәклектән буш булмаса да, ифрат көнче булуы, шөһрәт сөючәнлеге һәм кәпрәючәнлеге белән аерылып тора иде. Белем алу белән шөгыльләнгәндәй итеп, ялган сүз таратып, кешеләргә яла ягып, гомерен бушка уздырды һ.б.».

Хәзерге көндә дә бик мәшһүр кадими бер дамелла хакында берсеннән-берсе агулырак алты сыйфат белән сыйфатлавын тәмамлый. Әүвәлге берсе калсын, калган тиеше шулар: юләр, акылга җиңел нәрсә, көнче, ялганчы һәм фальсификатор! Башкалар турында да аның уенда булганын яшерергә, рия һәм икейөзлелеккә батып, буяулы гыйбарәләр кулланырга теләмәгәнлеге, һәр нәрсәне үз исеме белән атаганлыгы ачык күренә.

Хисаметдин Болгариның «Тарих»ын тәнкыйтьләүдә дә без шул Мәрҗанине җиңел таныйбыз.

Тәнкыйть шулай башлана:

«Тәварихел-болгария» исемле китаптагы ачык ялгышлар, әшәке ялганнар һәм вакыйгаларны буташтыру турында аңлатма бүлеге.

Китап иясе үз китабында әйтүенә караганда, ул – Казан өлкәсе, Чистай кальгасы тирәсендәге Ташбилге исемле авыл кешеләреннән, Мөслим баба нәселеннән, һиҗри белән мең ел үткән вакытларда яшәгән Хисаметдин бине Шәрәфетдин Мөслими дигән зат һ.б.».

«Тәварихел-болгария»нең язучысы бу әсәрне, галим Тафтазанидан дәрес укып кайткач, һиҗри 958 елда башлап, 992 елда тәмамлавын сөйли. Моңа каршы Мәрҗани язучыдан: «Һай, һай, әфәнде, бу әсәр өчен күпме гомерләр җентекләп тикшерү белән шөгыльләнгәнсез!» – дип ирония белән бергә, моның ачык ялган икәнен, аннан дәрес укыдым, дигән Тафтазани язучы Мөслимидән ничә гасырлар элек яшәп киткәнлеген, шуңа күрә, Тафтазани шәкертемен, дигән сүз катгый алдау икәнен сөйли. Соңра әйтә: «Әмма бу китап һәм бу китапка охшаган Болгар һәм Казан хәлләре хакында татар һәм башкорт муллалары төзегән һәм халык арасында таралган берничә китап бар. Барысы да – ачык ялган һәм вакыйгаларны бозып язылган хурлыклы хорафатлар. Бу «Тәварихе болгария» дә искә алынган сүзләрнең бер максаты, бәлки бер җөмләсе [дә] ялганнан, бозыклыктан сәламәт һәм вакыйгаларны бозудан азат түгел. Шуның белән бергә, халык, бәлки укучылар һәм кайбер аксөякләр каршында, таралган һәм кабул ителгән сөйләү һ.б.». Шул рәвеш[ле] башлап, бу тәнкыйтьтән максаты: «Тәварихел-Болгар»дагы уйдырма-экиятләрнең төпсезлеген ачу, андагы ялганнарны күрсәтү икәнен, калган маддәләре хәтта тәнкыйтьтән дә түбән икәнен сөйләгәннән соң, халыкны шул хакта бетмәс-төкәнмәс хаталардан коткарырга теләвен әйтеп, сүзен дәвам иттерә.

Кыскарак бетерү өчен маддә-маддә аерырга, хәрефкә-хәреф алмыйча, нәтиҗә генә бирергә мәҗбүрмен:

1. «Тәварихел-Болгар» айларның хасиятен сөйләгән вакытта әйтә: мөхәррәмнең унҗиденче көнендә язидиләр хәзрәти Хөсәеннең (Аллаһ аннан риза булсын) башын кисеп алып, Димәшкъ шәһәренә китерделәр. Язид баштан гафу үтенде, шулвакыт баш телгә килеп: «Мин Аллаһның хөкеменә ризамын, без үз эшебез, үз гамәлебез белән түгел, Ходаның язмышы белән үләбез. Мин кыямәт көнендә синнән кан дәгъва кылмам», – диде. Башны гәүдәгә кире ябыштырдылар. Ул тәмам әүвәлгечә утырды, тик яра эзе генә калды. Сәфәрнең егерме алтысында һиҗрәтнең илле алтынчы елында Кәрбәлада күмделәр. Шуңа күрә Язидкә ләгънәт укырга ярамый, ди.

Моңа каршы Мәрҗани кырт кисеп: «Бу сүзләр – һәммәсе, шиксез, ялган», – ди. Хәзрәти Хөсәеннең җирләнүе илле алтынчыда түгел, бәлки алтмыш беренче елда, мөхәррәмнең унынчы, Гашура көнендә икәне күптөрле юллар белән нык билгеле. Бу һәм хисапсыз күп китапларда шул рәвеш ачык бәян ителгән. Монда ике сүз булырга мөмкин түгел, ди. Шулай ук башта бәхиллек сорап, аның гафу итү вакыйгасы – баштанаяк ялган. Моны бәян [итү] турында китергән гарәп гыйбарәсе дә бөтенләй ялгыш һәм бозык. Язидме, Хәҗәҗ һәм шуларга охшаш затлармы – аларга ләгънәт кылу-кылмауның һичкемгә файда, зарары булу ихтималы юк.

2. «Тәварихел-Болгар» иясе хәзрәти Галинең җөмадиәләүвәлнең сигезендә туып, унбишендә вафат булганын, вафат булгач, бер кызыл дөя килеп чыгып, шуңа күтәртеп, «Бәкыйг»ның[5] бер почмагына җирләнүен сөйли. Мәрҗани моның да ялган икәнен ачып бирә: «Хәзрәти Гали – ди – һиҗри кырыгынчы елда, рамазанның унтугызында Күфәдә вафат булды. Бу хакта ике сүз юк. Һәммә китаплар шулай ди. Шулай ук

[5] «Бәкыйг» – изге сәхабәләр җирләнгән бер зират исеме.

туыйының да, әл-Мөсәлла әйткәнчә, җөмадиәл-әүвәлдә түгел, бәлки рәҗәб аенда икәнен, кабере дә Күфәдә икәнен бәян итә. Хәзрәти Галинең җирләнүе, кайбер сәбәптән, яшерен тотылды. Шунлыктан аның кабере хакында күп әкият бар. Берничә шәһәрнең һәрберсе аның үзендә булуын дәгъва кыла. Гадендә, Бәйнәл-җәбәләендә, Бәлехтә, Нур Асайда һәм башка берничә җирдә дип тартышалар. Бәлех янында аның кабере дип даими [рәвештә] бер таваф бара. Мавараэннәһер һәм Хорасан халкы шул җирдә хәзрәти Гали кабере булуына ышаналар, һәр ел шунда ике сукырның күзе ачыла, дип ышаналар икән. Мәрҗани моңа каршы әйтә: «Хәзрәти Галинең кабере шунда булуы, булган тәкъдирдә аның тәэсире белән сукырларның күз ачылу вакыйгасы акыл буенча булмаслык түгел, ләкин мәсьәлә урыннарда түгел, бәлки бар булуда. Моңарчы һичкем һичбер сукырның шунда килеп күзе ачылганын үз күзе белән күргәне юк, болар бар да шунда гади күңелне, халыкны җыеп, аларның кесәләрен талау өчен, каберлекләр саклаучы паразит дәрвишләрнең корган тозакларыннан башка нәрсә түгел».

3. «Тәварих» иясенең Болгар халыкларына бәйләгән бозыклыкларын Шиһаб хәзрәт: «Болар һичбер тарихи әсәр белән нык түгел, болар – һәммәсе уйдырма, болар – һәммәсе ялган, һәммәсе Болгар халкына яла ягу һәм аларны хурлау», – ди.

4. «Тәварихел-Болгар»да шундый бер вакыйга тасвирлана: ул заманда кызылбаш[лар]ның Мәшһәд исемле шәһәрендә Нәдершаһ дигән бер адәм чыгып, Бохара, Сәмәрканд, Үргәнеч, Хива һәм болардан башка күп «әһле сөннә вәл-җәмәга» мәзһәбендәге халыклы шәһәрләрне алды, голяманы үтереп, халыкны үзенең ялган мәзһәбенә өндәде. Шулвакыт Аллаһ Тәгалә Хозыр пәйгамбәрне җибәреп, Аксак Тимергә төш күрсәтә. Төштә шул Нәдершаһка каршы барырга әмер була. Ул гаскәр белән килеп, Нәдершаһның бәкләреннән берсен үтертә дә Бохарага юнәлә. Моны сизгәч, Нәдершаһ кача, Тимер аның артын-

нан җитеп, бер ел кадәр сугышалар. Нәдершаһ үтерелә, шәһәр харап була. Бохарага, аның атасы Сәлим ханны Нәдершаһ үтергән иде, дип, Солтанморад дигән берәүне хан [итеп] куя...

Моңа каршы Мәрҗани: «Ходаем, ни кадәр ялганнар, ни кадәр төзсез сүзләр», – дип хәйран була. «Беренчедән – ди – Тимер белән Нәдершаһ бер заманда яшәгән адәмнәр түгел. Тарих буенча катгый нык билгеле: Нәдершаһ Тимердән өч йөз ел соң Хорасанда дөньяга килде. Икенчедән, ул бу мәзһәбтә түгел. Аның гыйльми, мәдәни хезмәте күп. Голямага, «әһле сөннә»гә хөрмәтенең ни дәрәҗәдә зурлыгы тарихларда ярылып ята».

5. «Тәварихел-Болгар»да [язучы] Тимер белән Чыңгызны кызык очраштыра. Тимернең Аллаһ тарафыннан яхшылыкка өндәп, яманлыктан тыеп йөрергә җибәрелгән бер падишаһ сыйфаты белән күп җирләрне алгач, ул заманда Кытай падишаһы булган (?) Чыңгыз ханны дингә өнди, күп шәһәрләрне харап итә, үзен үтерә, урынына улы Торымтайны хан итеп куя һ.б. Мәрҗани моңа каршы: «Һай, ялганчы», – диюдән үзен тыя алмый һәм бу хикәядә ни дәрәҗәдә бозык ялганнар тулганлыгын исбатлый: «1) Аксак Тимер, Чыңгызның вафатыннан йөз ел үткәч, дөньяга килде; бәс, алар ничек очрашып, сугышалар, үзеннән йөз ел элек вафат бер адәмне Тимер ничек иманга өнди дә, килмәгәч, ничек үтерә; 2) тарих белән мәгълүм, Чыңгызның дүрт улы бар: Җүҗи, Чыгтай, Түли һәм Үктәй, әмма Торымтай дигән улы һич булганы юк».

---

Мин Шиһаб хәзрәт тәнкыйтенең кайбер маддәләрен генә сайлап алам. «Тарихел-Болгари» хакында бүген андый тәнкыйть язып маташу көлке булачак. Ләкин Мәрҗани дәверендә тарихтан хәбәрсезлек шул дәрәҗәдә иде ки, шул баштанаяк экият, хорафат һәм ялгыш уйлар белән тулган «Тәварихел-

Болгар» могтәбәр бер китап булып, кулдан кулга йөри иде, аның сүзләре хакыйкатькә алына иде. Заманындагы һәрбер туңлык белән, фикердә әсирлек һәм хорафат белән көрәшә килгән Мәрҗанигә бу тарихны тәнкыйтьләве – шул күп хезмәтенең бик табигый бер кисәге.

Аның тәнкыйтен мин бөтенләй китерә алмадым. Ул үзе дә әсәрнең һәр маддәсенә аерым кагылмаганын, тик мөһимрәк табылганнарына туктаганын сөйли һәм әйтә: «Хисаметдин бине Шәрәфетдин Болгариның китабында булган ялгышлар һәм ялганнары чиктән тыш күп. Калдырмыйча бәян ителгән тәкъдирдә, берничә зур китап язарга кирәк булачак. Ул кадәр артык эштән тыелып, аңлатуның бу кадәресе белән чикләнеп, калганын акыл ияләренең үз фикерләренә йөкләп калдырылды. Аллаһ – дөреслекне белүче, Анда сыену урыны һәм Ул миңа Ярдәмче буларак җитә.

*«Аң» журналы. – 1915. – № 2. – Б. 39–47.*

*Ризаэтдин Фәхретдин*

# «Мәрҗани»

«Мәрҗани» – үз гасырында ислам дөньясының галиме булган Шиһабетдин Мәрҗани хәзрәтләренең дөньяга килүенә йөз ел тулу мөнәсәбәте белән нәшер ителгән бер әсәр. 639 биттән гыйбарәт булган бу әсәрдә Мәрҗани хәзрәтләренең кул-язу клишәсе, мәчете, үзе торган йортының, үзенең, мәдрәсәсенең рәсемнәре бар. Бөтен китап бу бүлекләргә аерыла: 1. Мәрҗанинең тәрҗемәи хәле. 2. Мәрҗанинең гыйльми хезмәтләре. 3. Мәрҗани хакында мәкалә һәм хатирәләр. 4. Төрлеләр.

[...].

Мәрҗани хәзрәтләренең тәрҗемәи хәле ителеп язылган бу әсәр – хакыйкать хәлдә, бер гыйлем чишмәсе. Бәяли белүчеләр өчен файдаланырга һәм тикшерергә тиешле булган бәхәсләр һәм мәсьәләләр монда күп.

Мәрҗани хәзрәтләренең төрле әсәрләрендә һәм төрле мөнәсәбәтләр белән сөйләнгән сүзләре, шушы китапта тулы ысуллар рәвешенә куелган һәм төрле темалар, үзләрен терки торган кагыйдәләр асларына җыелган. Бу турыда әйтелергә тиешле булган хезмәтләр тәмам җиренә килеп җиткән, төзәтелеп һәм тулыландырып беткән булмаса да, бик файдалы бер юл башланган һәм җимеше күренәчәк бер юл күзәтелгән. Шул яктан китапны төзүчеләрнең хезмәтләрен танырга мәҗбүрмен.

Русия мөселманнары арасында башка мәмләкәтләрдә дә Шиһабетдин һәм Зыятдиннәр, Шәмсетдин һәм Таҗетдиннәр хисапсыз дәрәҗәдә күп икәнлеге мәгълүм. Ләкин ислам динен

бидгатьләрдән сафларга, кәлям әһелләренең[1] уйдырмаларыннан аерырга, гомумән, ислам динен сәләф[2] гасырында булган рәвешенә кайтарырга тырышучы һәм бу юлда җәфа-мәшәкатьләр тартучы Шиһабетдиннәребез күп түгел.

Дөрес, безнең Шиһабетдинебезнең гомере дә гыйлем базарындагы дәрәҗәләре түбән адәмнәр белән дәгъвалашып һәм шуларны кире кагып үтте, бик зур адымнар атларлык әзерлеген юк җирләргә сарыф итәргә мәҗбүр булды. Юкса Шиһабетдинебез тагы да файдалырак, гомумирәк хезмәтләр күрсәтергә яраклы булган булыр иде, ләкин моның гаебе Мәрҗанидә түгел, бәлки заман һәм тормыш иткән урыннар, гомумән, мохит өстендә.

Юкса Мәрҗани әгәр дә сәләф гасырында булган исламны күрсәтеп Сәгыйд бине Мөсәйййиб һәм Зөһри, Малик һәм Әүзәгый, Әбү Хәнифә һәм Әхмәд бине Хәнбәл, Шафигый һәм Шөгъбә, Яхъя бине Мәгыйн һәм Ибне Мөнзир, Әбү Йосыф һәм Габдулла бине Мөбарәк, Мөхәммәд бине Хәсән һәм Ләйс бине Сәгъд һәм дә шулар дәрәҗәләре каршыларында билгеле булган юлны ачык бәян итеп, бер әсәр төзегән булса иде, «Гакаид нәсәфия» шәрехләре, «Гакаид гадудия» һәм «Тәүдыйх» хашияләренә[3] караганда, файдалы булган булыр иде. Ләкин бу турыда Мәрҗани гозерле иде. Инде бу хезмәтләр башкаларга йөкләнә.

Ислам дөньясы өчен котылу юлы бер генә, аның тармагы, фәләне дә юк. Ул исә сәләф гакыйдәсен һәм сәхабәләр, табигыйннар һәм шуларга гасырдаш галимнәр кабул иткән юлны сайлаудан гыйбарәт. Сәләф гасырында булмаган гакыйдә һәм гамәлләрдән, тарикать һәм юллардан, тузан кадәр генә булса да, файда булыр, дип белмибез.

Мәрҗани, гәрчә дөньяга шушы исем белән чыкмаса да, хәтта хәнәфиләргә тарафдарлыкта фанатизм һәм чамасызлык белән яла ягылуга дучар булса да, хакыйкать хәлдә, аның юлы-

[1] Кәлям әһелләре – дини ышануларны сай акыллары аша аңлатырга тырышучылар, мәсәлән, җәһмиләр, мөгътәзиләләр, әшгариләр, матүридиләр.
[2] Сәләф – борынгы изгеләр, ягъни сәхабәләр (пәйгамбәр иярченнәре).
[3] Хашия – китап читләренә язылган аңлатма.

на караганда, Коръән, Сөннәткә[4] тотыну һәм шулардан башкаларны танымау тиеш килеп чыга. Сәләф гакыйдәсе дә шуннан гыйбарәт. Әбү Хәнифә белән Әбү Йосыф та шуны дәгъва кыла. Вафаты вакытында Әбү Йосыфның: «Илаһым! Коръән, Сөннәт һәм бөтен мөселманнар сүзенә туры килгәненнән тыш, бөтен фәтваләремнән кире кайттым», – дип тәүбә итүе билгеле.

Ислам дөньясында «әһлес-сөннә вәл-җәмәга» юлының исеме белән укыла торган гакыйдә китапларының «әһлес-сөннә вәл-җәмәга» юлы булудан бигрәк, кәлям әһеле, ягъни әшгари һәм матүридиләр юлы икәнлеген, анда булган темаларның Коръән һәм Сөннәткә яраклы булудан бигрәк тә, мөгътәзиләләрне кире кагуны нигез [итеп] тотылганлыгы аңлашылырга һәм шушы фикерне Аллаһ ризасы өчен һичкемнән курыкмый сөйләргә тиешле иде. Хәлбуки, Әшгари юнәлешендә булган фирка башлыклары хакында шул юнәлешләреннән тәүбә итүләре, кәлям әһелләре юлында аз гына да хәерле эш юклыгын танулары һәм җан-тәннәре белән Коръән-Сөннәткә сыенулары риваять ителә һәм дә бик ышанычлы кешеләр моңа шәһәдәт бирәләр. Инде фирка башлыклары бу эшләреннән тәүбә итеп котылсалар һәм җаваплылыктан азат булсалар, иярченләренең хәлләре ничек булыр..? Шушы турыда фикер йөртергә, инсафлык белән хөкем чыгарып карарга тиешле иде.

«Мәрҗани» исемле әсәр нәшер ителүе шушындый эшләргә җирлек әзерләсә кирәк, дип өмет итәбез һәм шуның өчен дә әзерле, гыйлемгә гашыйк, инсафлы, тәрбияле яшьләрдән Мәрҗанинең бу китапта сөйләнгән юнәлешләрне тәнкыйтьләүләрен көтәбез. Боларны тәнкыйтьләү нәтиҗәсе Американы табу булмас, әмма ислам дөньясы өчен Америка табудан да әһәмиятле һәм файдалы нәрсәдән гыйбарәт булыр. Иншалла!

*«Шура» журналы. – 1915. – №9. – Б. 283–285.*

[4] Сөннәт – Мөхәммәд пәйгамбәрнең өйрәтмәләре, гамәлләре һәм сүзләре.

*Борһан Шәрәф*

# Мәрҗани хакында җавапларым

«Шура»ның 11 нче номерындагы Габдулла әфәнде Биги тарафыннан бирелгән сораулар эчендә Мәрҗани хәзрәтләренә караган 3 юлы күп укучыларның күзләренә чалынмый калган булырга кирәк. Юкса ул мәшһүр галим турысында язар өчен күп укучылар берничә сүз тапкан булырлар иде.

Мәрхүмнең иярченнәреннән Х. Үтәки җәнаблары «Шура»ның 23 нче номерына кертелгән җавабы белән онытылган сорауны искә төшерде. Олуг галимебезнең вафатына 25 ел тулу мөнәсәбәте белән үз дәрәҗәсенә яраклы рәвештә юбилей ясау мәсьәләсе дә кузгалып торган чакта, аның хатирәсенә берничә күзәтүләр язып, Габдулла Биги әфәндегә мин дә җавап бирәчәк булдым. Аның сораулары: «Мәрҗани хәзрәтләренең милләтебезгә күрсәткән хезмәтләре ни нәрсәләр? Тараткан фикерләренең тәэсире үзе дөньяда чакта күренгәнме?» – дигәннән гыйбарәт иде. Мин Шиһаб хәзрәтнең берничә хасиятьләрен түбәндә искә алып, шуңа җавап чыгармакчы булдым. Хасиятьләре шулар:

1. Шиһабетдин Мәрҗани хәзрәтләре Бохарада укып та, аннан канәгатьләнмәгән һәм шуны бөтен дөньяга игълан иткән кешеләрнең беренчесе булды. «Бохар күргән» кешеләр һәммәсе үзләренең камиллекләренә, мәдрәсә һәм остазларының олуглыгына алданып йөргән, халык та шуларны хаклап һәм яклап торган бер заманда Шиһаб хәзрәтнең бу каһарманлыгы бик олуг бер хезмәт иде. Соңра татарларның Бохарага карашлары бөтенләй алмашынуга сәбәп булды.

2. Шиһаб хәзрәтнең гыйлем һәм камиллеккә ихтирамы, аңа юнәлүе һәм аның алдында тез чүгүе мәрхүмнең үзен дә кул астына алган, үз шәхси мәнфәгатьләреннән, вак дөнья теләкләреннән өстен иткән. Шуңа күрә гыйлем һәм хакыйкать аннан, ягъни гыйлем хадименнән бер нәрсә таләп итсә, ул шуңа: «Ләббәйкә!» – дип, шартсыз, ык-мыксыз җавап биргән. Бу хакта халыкның яратмавы, голяманың һәм муллаларның каршы килүләре аңа чүп булып кына күренгән. «Алар Аллаһ юлында сугышырлар һәм куркытып шелтә кылучыларның шелтәсеннән курыкмаслар» [Коръән, 5:54] аятен искә төшерерлек булган.

Шиһаб хәзрәт белгән нәрсәләрне ул заманда белүче булмаган, димибез. Ул аңлаган мәсьәләләрне аңлаучы үзе генә булган, дип әйтсәк, хата булыр. Әмма ул әйткән сүзләрне башкалар әйтә алмаган, ул ачкан хакыйкатьләрне башкалар ябып тотканнар, бәлки хәзергәчә дә караңгы калган булырлар иде, дип әйтә алабыз. Башка белүчеләрнең ышанулары анык дәрәҗәсендә катгый була алмагандыр, дип уйларга юл бар.

Аллаһ сыйфатлары мәсьәләсендәге дәгъвалары, ястү намазы мәсьәләсендәге «Назурә»се, дүрт тугры хәлифәнең өстенлеге мәсьәләсендәге бәхәсләре, хөтбә, җомга намазыннан соң өйлә намазын уку мәсьәләсендәге катгый бәяннәре, Бохараның билгеле укыту ысулларын тәнкыйтьләве, шәрех һәм хашия исемендәге чүп-чарларны игътибардан сөбереп-түгеп, Коръән, хәдис һәм чын голяма әсәрләрен күтәрергә тырышлыгы, һәрбер мәсьәләдә хөкем һәм тикшерүне алга чыгарып, тәкълид[1] һәм гадәтнең хакимлегенә һөҗүм ясавы, Тәфтазаниларның фикерләрен танытуы – ул олы галимнең никадәр батыр һәм хаклык өчен никадәр гайрәтле һәм фидакяр икәнлегенә ачык дәлилләр. Бу мәсьәләләрнең берәм-берәм халыкның прогрессына һәм дин эшенең алга китүенә ачык рәвештә күп тәэсир күрсәтмәсә дә, галимнәребезнең хәзинәсендәге нәрсәләргә яңадан бәһа куеп чыгу булганлыктан, бездә фикер туга, безнең милли һәм

[1] Тәкълид – дин галимнәренең сүзләренә сукырларча иярү.

иҗтимагый тормышыбыздагы алмашынуларга башлап зур сәбәпче булды.

Иҗтиһад заманының үтмәве мәсьәләсен киң сурәттә мәйданга куюы үзе генә ни тора! Төркия, башта бик күп ислам мәмләкәтләре бу хакта Русиядән көнләшергә тиешләр. Имам Әбү Хәнифәнең: «Алар – кешеләр, без дә –кешеләр», – дигәнен аңлап, шуны татарларга да аңлатырга тырышу аз хезмәтмени? Бу хакта Курсави хәзрәтләренең дә хезмәтен онытмыйбыз. Ләкин халыкка тәэсир [итү] Мәрҗанидән булды. Курсавиның «Әлиршад» һәм «Шәрхе гакаид»лары басылып, мәйданга куелганда инде базарның кызуы үткән иде. Шуңа күрә ул әсәрләрнең чыгуы аз гына да имеш-мимешкә сәбәп булмады. Шау-шуның барысы Ташкичү каһарманы колагына яңгырап беткән иде.

Кечкенә генә ике эш: А. Шиһаб хәзрәт үзенең хисабы белән Казанда ике мәсчетнең михраб урынын алмаштырган. Чөнки бу мәчетләр кыйблага кыек салынган булганнар. Хәзерге һәм элекке замандагы «уйлап эшләүче» муллалар, гади халыкның «кыйбланы үзгәртте» дигән сүзен ишетмәс өчен, бу хәрәкәттән сакланырлар иде, дип уйлыйм. Б. Сөйләүләренә караганда, Шиһаб хәзрәт урамда, мәсәлән, өеннән чыгып мәчеткә барганда авыз эченнән берәр дәрес кабатлап барып, кешеләрнең сәламен дә алмый торган булган; мәчеттә намаз көткәндә Коръән я башка китапны уку белән мәшгуль булган. Бу эшләр зур камиллек түгел, әмма моның өчен гади халыктнан өстен тору кирәклегендә шөбһә юк. Хәзерге һәм элекке заманда «сәясәтле» голямалар, мәчеткә кергәндә һәм чыкканда, берничә кешеләр белән исәнләшеп-сөйләшеп, аларның «хәтерләрен табу»ны камиллектән саныйлар түгелме?

3. Татарлардан галим сыйфаты белән чит мәмләкәтләрдә танылган кешеләрнең иң беренчесе Шиһабетдин Мәрҗани булды. Мәдрәсәдә һинд басма китабының битләре читендәге кыек язуларын ихласлык белән укыган заманымда, шул китапта бер мәсьәләгә дәлил өчен «әл-фәзыйлү Шиһабетдин әл-Мәрҗа-

ни»нең фикере аерым язылганын күрү миңа шулчаклы шатлык булды, татарлык өчен шулкадәр горурландым ки, тизрәк кычкырып, иптәшләремне җыеп, китапның шул урынын күрсәтмичә чыдый алмадым. Ул китапта татар галимен искә төшерүченең кем икәнен белергә телисезме? Рәхим итегез: Мәрҗанинең сүзе белән дәлил итүче кеше һинднең иң зур һәм иң мәшһүр галимнәреннән имам Габделхәй әл-Лүкнәви иде.

Мәрҗанинең Истамбулда, яхшы дип табып, бастырылган «Мулла Җәлал» хашиясен актарганда, мәшһүр тарихчы Нәҗип Гасыйм бәкнең «Төрек тарихы» әсәрендә Мәрҗанидән күчерелгән сәхифәләрне укыганда, шул ук милли горур хис ителә. 1874 елларда Лондонда бер китап фирмасы «Гомуми энциклопедия сүзлеге» бастырганда, мәшһүр кешеләр арасына Шиһаб хәзрәтнең тәрҗемәи хәлен тәкъдим итәр өчен, хат белән аның үзенә мөрәҗәгать иткән, бу хакта материал сораган. Бу хат хәзергәчә мәрхүмнең варислары кулында саклана.

4. Шиһаб хәзрәт заманында бик таралган бер фикер – мөселманнарның Русиядә алга китүенннән өмет өзеп, Төркиягә күченү кирәклеге – булган. Казанның иң мәшһүр мөдәррисләреннән Кәрим хәзрәт һәм башка күп кешеләр, шул фикергә нигезләнеп, күченгәннәр. Ләкин Шиһаб хәзрәт Русиядә татарларның алга китүләре мөмкин икәнлеге фикерендә булып, шуның юлларын күрсәткән. Бу мәсьәләдә хаклык кай тарафта булганы ул заманда караңгы булса да, уңыш һәм турылык аның тарафында булганы хәзер көн кебек ачык.

5. Шиһаб хәзрәттән элек гыйлем эше мулла һәм мәдрәсәләргә хас кебек булган. (Элекке заманда христианнар гыйлемне монастырьга япкан кебек). Ул исә гыйлемне мәдрәсә почмагыннан чыгарган. Аның дәрес бирү түгәрәгендә файда алучылар күп булса, дәресендә китап ачып утырмыйча аннан файда алучылар янә күбрәк.

Казанда Сәлах хәзрәт шәкерте һәм «Мәрҗани» мәдрәсәсенә дошман булган мәдрәсәгә караган мәшһүр Галимҗан хәзрәт [Баруди] үзенең Шиһаб хәзрәттән файда алуы, Казандагы башка остазлардан файда алуына караганда, артыграк булганны горурлану белән искә ала. Казанда сәүдәгәр, морза һәм гади халык сыйныфына карап, Мәрҗани янында камиллек тапкан кешеләр күп булган. Гыйлемнең мәдрәсә бүлмәләреннән һәм чаршауларыннан читкә чыгуы, ягъни гыйлемнең халыклашуы берничә ун еллар элек мәйданга куелу сәбәпле, хәзерге заманда указсыз һәм «вазыйфаларсыз» кешеләр арасында да шундый галимнәр табыла ки, бу хәл белән милләтебез өчен горурланмаска мөмкин түгел.

6. Аның тарихка хезмәте, милләтебез эчендә нигезле булып, тарихка хезмәтнең беренчесе булганлыктан, никадәр бәя бирелсә дә, урынында, ләкин мәрхүмнең бу юлдагы хезмәтләренең бер өлеше генә мәйданга чыгып, бик күп хезмәт һәм мәшәкатьләреннән һаман да файдаланылмаган көе торыла. Варислары, аннан соң килгән буыннар, эшкә килгәндә суына торган ваемсыз ихласлылар аның әсәрләрен мәйданга чыгаруны булдыра алмый торалар.

Сүз чыкканда шуны искә төшерик эле: «Шиһаб ахун»ның кабер ташы берничә заманнар Казан зиратында иң гүзәл таш булып торган иде. Инде таш өстендәге тулы айның алтыны бетеп, бөтенләй кызганыч хәлдә калган. Ялланып хаҗга йөрүче берәүнең каберенә чардуган ясаган Казан халкы Шиһаб ахун каберенә тиешенчә хатирә ясый алмый. Аның ташын да төзәттермиләр. Мәрхүм үзе кабер ташларының кадерен бик белүче, аларны эзләп сәфәр чигүче, һәммәсен дикъкатьләп өйрәнүче булган.

Югарыда искә алынган алты маддәгә өстәләчәк нәрсәләр янә бик күп. Тәрҗемәи хәлләрен аңлатуда, әлбәттә, күренер. Ләкин бу кадәресеннән дә югарыдагы сорауларга җавап чыга.

Шиһаб хәзрәт галим, гыйлемгә ышанучан, гыйлемнең кирәклеген гади халык фикереннән югары тота ала һәм шулай тота, гыйлемгә тырышлыклы һәм аның өчен гайрәтле кеше булган. Үзеннән соңгыларның күз алдында гыйлемнең дәрәҗәсен күтәргән. Чит мәмләкәттә татар исеменең, гыйлемгә бәйләп бәйләп, телгә алынуына сәбәпче булган. Бик күп гыйльми мәсьәләләрне мәйданга куеп, тикшерү һәм хөкем чыгаруның кадере беленә башлауга, иске хәзинәбездәге нәрсәләрне актарып, бәһаләрен тикшерүгә сәбәпче һәм кузгатучы булган. Болар аз хезмәт түгел. Боларның әсәрләре дә күз алдында.

Без – Мәрҗани хәзрәтләрен күрмәгән, аның янында булучылардан гына әсәрләнгән кешеләр «олуг абыз»ны шулай таныйбыз.

*«Шура» журналы. – 1911. – № 24. – Б. 757–759.*

*Габделбари Баттал*

# Мәгънә һәм хакыйкать эзләүче галим

Казаннан бер фазыйл[1] чыкты алмас булып,
Хасидләре[2] күбәйде гам-хас[3] булып,
Мәгани җәваһирен[4] кулга элгән,
Хакаикъ[5] диңгезендә гаувас[6] булып.

**Акмулла.**

Башлап тәрҗемәи хәлен язарга һәм шигырьләрен тупларга бәхетле булган шагыйрь Акмулла соңгы шигъри юллары белән Мәрҗани хакында иң мөһим бер ноктаны игътибарга алган: «Мәгани җәваһирен кулга элгән, хакаикъ диңгезендә гавас булып». Чыннан да, моннан 70 еллар элек, ягъни Шиһаб хәзрәт, укыту һәм әсәрләр язу белән бәйләнергә тотынган заманнарда безнең «голяма» исеме белән аталган затларыбыз арасында мәгънә һәм хакыйкать эзләү бөтенләй диярлек кулланыштан төшкән; гыйлемнәрне һәм өлгергәнлекләрне Бохарада алган безнең дин галимнәребез, гомумән, сүзләр, агымнар һәм хыяллар белән чуалып торалар иде. Ул чакта безнең мәдрәсәләребез бәхәсләшүләр белән шаулап торсалар да, бу бәхәсләр һичбер

[1] Фазыйл – хөрмәтле галим.
[2] Хасидләре – көнләшүчеләре.
[3] Гам-хас – җәмгыятьнең бөтен катламы.
[4] Мәгани җәваһирен – мәгънәләр җәүһәрләрен.
[5] Хакаикъ – хакыйкатьләр.
[6] Гаувас – суга чумучы.

гыйльми кыйммәте, мәгънә һәм хакыйкать эзләү юлында һич әһәмияте булмаган юкка лаф орулардан, бер шәрехләүче яки китап язучының бер җөмләсе хакында юкка сүз көрәштерүләрдән гыйбарәт була иде. Фән белән динне бергә болгатудан гыйбарәт булган грек схоластикасының «шулпасының шулпасы», ягъни бөтенләй рух һәм мәгънәдән азат булган бер пародиясе, Мәрҗани хезмәт мәйданына чыккан заманнарда безнең мәдрәсәләребездә деспотларча хөкем сөреп тора иде.

Безнең укыту йортларында фән юк, чын мәгънәсе белән дини гыйлемнәр дә юк иде. Бу сүз арттыру дип йөртелмәсен. Безнең мәдрәсәләребездә математика, табигать белемнәре, тарих укытылмаганлыгы, Коръән һәм хәдис гыйлемнәре, ислам тарихы, пәйгамбәр тормыш юлы һәм сыйфатлары, җитди рәвештә фикыһ[7] нигезләре, фикыһ укытылмаганлыгы һәммәбезгә мәгълүм. Мәдрәсәләребездә ике нәрсә кулланышта иде: мантыйк, кәлям. Менә бу соңгысы – схоластиканың үзе.

Мәгънә һәм хакыйкать эзләүче Мәрҗани курсын кичте, ләкин анда һичбер мәгънә һәм хакыйкать тапмады, димәк, ул үзенең батыр табигатенең юнәлтүе белән «кәлям» дигән нәрсәгә һөҗүм итте. Мәрҗани хәзрәтләренең кәлямне ни дәрәҗәдә ялганлыгын фаш итүен һәм аны менеп утырган урыныннан төшерергә ни дәрәҗә тырышканлыгын аңлар өчен, ул затның «Назурәтел-хак», «Әл-хикмәтел-бәлигатил-җәнния» дигән китапларының баш бүлекләрен уку җитә. Дөрес, Мәрҗанинең бу һөҗүмнәре гарәп теле белән язылган, ләкин ул чакта бездә гыйлем теле гарәпчә булу сәбәпле, мәсьәләне әһеле (голяма һәм шәкертләр) аңлый иде.

Һич шөбһә юк ки, арабызда күптән түгел кузгатылган кайбер бик зур гыйльми-дини мәсьәләләр кебек, базарларга, толчокларга барып кермәсә дә, Шиһаб хәзрәтнең кәлямга булган һөҗүмнәре әһелләре каршында зур тәэсирләр тудырды.

[7] Фикыһ – ислам хокукы.

Шулай итеп, бөтен акыл һәм фикерләребезне шөгыльләндереп, гыйлем йортларыбызны басып алып торган схоластика (кәлям) кошмарына беренче сугуны төшерүче Шиһабетдин Мәрҗани хәзрәтләре булды.

Мәрҗани даими рәвештә игътикад бабында изге сәләфләр юлында булырга өнди. Ул бу эше белән дә кәлямгә кагыла: «Әгәр мөэмин булсаң, ышанырга тиешле нәрсәләргә изге сәләфләр кебек ышан, ләкин саклан: «фәннәр»не «игътикадлар» белән болгатма!

Мин Мәрҗанинең кәлямгә каршы ачкан бу сугышын гыйльми һәм иҗтимагый тарихыбызда бик мөһим урын тотарга тиешле бер хезмәт дип беләмен.

Шиһаб хәзрәтнең милләтебезне билгеләү юлында тикшерүләре татар милләте икәнлегебезне исбат итүе, ислам тарихына караган туры һәм нигезле фикерләре, кайбер ышанулар, гыйбадәт йолалары хакында кабул ителгән күп ялгышлыкларга каршы каләм йөртүе – һәммәсе аның мәгънә һәм хакыйкать эзләүче бер зат булганлыгын күрсәтә.

Мөселман дөньясында дини эшләрдә һәм шуның тәэсире белән иҗтимагый эшләрдә дә тәкълид һәм торгынлык хөкем сөреп торган бер заманда, шул тәкълид һәм торгынлыкка каршы милади XIX гасырның яртысында аркылы төшеп тавыш күтәрүче ислам галимнәренең берсе, шөбһәсез, Мәрҗани хәзрәтләре. Мөҗәддид[8] дип атарга да ярый, ләкин һәрхәлдә Мәрҗани хәзрәтләре батыр бер каршы төшүче һәм хакыйкать эзләүче бөек бер бәхәсләшүче.

Бөтен голямабыз каршында авторитет саналган күпләрне тәнкыйтьләп, күп кабул ителгән начар игътикадлар һәм акылсыз карашларның ялганлыгын фаш итеп, Мәрҗани хәзрәтләре бездә, акылларда тәнкыйть куәсен уятты, фикерләргә хәрәкәт бирде. XIX гасырда туңган татар дөньясын эретергә, караңгы

[8] Мөҗәддид – динне элекке саф хәленә кайтаручы.

почмакларыбызга зая җибәрергә тотынган ирләребезнең иң алдынгысы – шөбһәсез, Мәрҗани хәзрәтләре. Бу затның моннан 60–70 [ел] элек иске карашларга һәм фикер туңгылыгына каршы сүз әйтә башлавы, аның гаять үткен тәнкыйтьләүче акылга ия һәм хакыйкать сөюче бер зат булганлыгын ачык күрсәтә.

Һәр эшендә китап сүзе белән генә йөргән һәрбер «китап язучы рахмәтуллаһи галәйһи»нең сүзен «ышандык һәм расладык» дип кабул итәргә өйрәнгән, үзләренең көч һәм гыйльми дәрәҗәләренә бик нык ышанган адәмнәр Шиһаб хәзрәткә каршы аякландылар, яклаучыларның һәрбер яңа фикер, һәрбер яңа агымга каршы төшүләре бик табигый. Ләкин хакыйкать һичбер вакытта басылып калмый, табигый нәрсәне һичбер кеше туктата алмый. Шиһаб хәзрәтнең мәгънәсез һәм файдасыз эшләргә каршы чыгуы, бәхәс һәм тәнкыйтькә өндәве җилгә китмәде. Мәрхүм милләт улларының башына туры фикерләр, йөрәгенә якты өметләр керүгә җирлек әзерләде. Татарларның иҗтимагый сәламәтлеген, матур киләчәген теләп, эш күрүче яшь буын, үзенең олуг остазы Мәрҗанигә дә бурычлы. Милләтләрнең алга китүе, иҗтимагый эшләрендә яңа юлларга кереп китүе сәбәпсез һәм кинәт булмый. Болар төрле эшлекләр, төрле вакытлардагы төрле сәбәпләр аркасында мәйданга киләләр. Мыжлап яткан схоластика, ваемсызлык, масаю һәм эгоизм оясына таяк тыккан, динне ялгыш аңлатып, бөтен бер милләтне «адашканнар адашуы» эчендә тоткан кешеләргә каршы аркылы төшү белән аякка баскан, милләтнең үткәнен-тарихын тикшереп, үзебезне үзебезгә таныткан, рус теле һәм мәдәниятенә мөнәсәбәтебезнең башка төрле булырга тиешлеген сөйләгән Мәрҗанинең бездә фикри инкыйлаб тууда тәэсире булмаган, дип кем әйтә алыр?

Шиһаб хәзрәт башка ислам мәмләкәтләрендә дә танылды, аның исеме бөек ислам язучыларының мөһим әсәрләренә керде, рус дөньясында да, Европада да телгә алынды. Димәк, Мәрҗани

без татарларның дөньяга яхшы исеме чыгуына, фән һәм мәдәният дөньясында танылa башлануына да сәбәп булды. Шунлыктан без бөек остаз Шиһабетдин Мәрҗани хәзрәтләренең исеме белән башка мәмләкәтләрдәге мөселманнар һәм руслар, европалылар алдында мактана да алабыз. Чыннан да, Шиһаб хәзрәтнең безгә милли бер мактана ала торган нәрсә икәнлеген мәкаләмнең башында бер шигырен күчергән Акмулла да аңлаган. Ул аның хакында әйтә:

Мәйданга ул чыгарды артык гайрәт,
Мизмарда[9] сабикълардан[10] чыкты гасрәт[11];
Хәмде лилләһ[12], бу диярда[13] бездән чыкты
Мәржани Шиһабетдин ахун хәзрәт!

*«Йолдыз» газетасы. – 1915. – 9 гыйнвар. – Б. 1–2.*

[9] Мизмарда – чабу мәйданында.
[10] Сабикълардан – элекке кешеләрдән.
[11] Гасрәт – абыну.
[12] Хәмде лилләһ – Аллаһка мактау.
[13] Диярда – дөньяда.

*Габдулла Гыйсмәти*

# Бүген йөз ел тулды

Ислам галәменең түбән төшүенең баш сәбәбе – ислам дине, дип уйламыйча сөйләүче затлар булсалар да, ислам тәгълиматын белүче кешеләр, мөселманнарның аскы, түбән дәрәҗәдә калуларын таныган хәлдә, түбән төшүгә сәбәпне башка җирдә күрәләр.

Бер милләтнең түбән төшүе кебек сәяси, иҗтимагый, тарихи һәм рухи мәсьәләгә дини сәбәпнең караш ноктасыннан караганда, югарыда әйтелгән соңгы фирканың фикеренә кушылабыз һәм бу урында шул караш ноктасын аңлатмакчыбыз.

Ислам тарихына күз салсак, бер-берсенә нигездә каршы ике дәверне күрәбез: фикердә хөрлек һәм фикердә коллык.

Беренче дәвергә караган кешеләр, дин – рухны тәрбияләүче, кешеләр бәхетенә хезмәт итүче, дип караганлыктан, кеше тормышында беренче сәбәп булган акыл даирәләренә киңлек, иркенлек бирү тарафында иделәр, кешегә бирелгән акыл нигъмәтен юк итүгә, бөтен булган нәрсәләрне тулы һәм өлешчә рәвештә эченә алган фикер диңгезенә җирәнгеч нәрсәләрне ташлап, мохитен киметү, бетерү җинаятенә төшүдән качалар иде. Шунлыктан бу дәвер хөкем сөргән чакта ислам галәме парлак, һәркем хөр, рухи яктан олы, хезмәте дә бөек иде.

Төрле сәбәпләрдән, бу бәхет дәвере бетүгә йөз тотты; акрынлык белән, ләкин куркыныч сыйфатлы икенче дәвер яки тәклид дәвере баш күтәрә башлады, бәхет дәверенең һәрбер малын һәлак итүгә, кеше асылын югалтучы рух түбәнлеген, хыянәт,

җинаять, куркаклыкны идеал итеп күрсәтте. Исламның бу дәверендә илаһ дәрәҗәсенә җиткерелә язган затлар, нәрсәләр дә күбәйде. Мәгънәсез шәкелләр белән тулы кәгазьнең, ишан кулыннан чыккан ташлар, җиде тыкрык чатына ыргытылган алама чүпрәкнең, күрәзәчеләрнең алдаулары белән пәрдәләнгән суның шәрәфәтенә, изгелегенә ышану күп кешенең идеалы дәрәҗәсенә җитте, дине булып әверелде; боларга ышанмаган кешеләр мөселман түгел булып хисапландылар; аларга кимсетү күзе белән караучылар җәһәннәмдә мәңге калуга хөкем ителгәннәр дәрәҗәсенә ирештерелделәр. Беренче дәвердә җәннәт белән сөендерелсә, икенче дәвердә җәһәннәм иң зур хөкем сөрде.

Бу тәкълид дәверләре җәһәннәм дәвере, бидгать падишаһлык сөргән дәвер иде. Менә шул дәвернең соңгы көннәрендә мәрхүм Шиһабетдин Мәрҗани хәзрәтләре туды, шул дәвердә яшәде, шул дәвердә хезмәт итте, ләкин дәверенә, заманына бөтенләй башка юл, башка рух белән.

Мәрҗани хәзрәтләре, мөбарәк билләрен бәйләп, хөрмәтле җиңнәрен сызганып, тәкълид дәверен бетерүгә, җәһәннәм азыгын киметүгә, бидгать-начар гамәлләрдән котылырга кереште, безнең өчен дә «иҗтиһад бетте, акылының алга этәрүе, фикеренең күрсәтүе буенча кешенең йөрүе хәрам, уйлауга берәүнең дә хакы юк», дигән явыз игътикад белән көрәшүгә кереште.

Бу сөйләнгән мәгънәләр яхшырак аңлашылсын өчен аларны ачыграк сөйлик.

Тәкълид дәверендә хөкем сөреп, һәркемнең тормышын коллык дәрәҗәсенә китерүче голяма сыйныфының уе болай иде: «Мөҗтәһидләр[1] ни әйтсә, тагын ачыграк итеп әйтик, Ибне Габидин, башка фикыһ китапларында, «Гакаид Нәсәфия шәрехе» һәм игътикад юлында нигезсез язылган игътикад китапларында ни диелсә – шул һәркемнең юлы, һәрберәүнең игътикады булыр; бу китапларда күренгән нәрсәләр тәрбияле акылга каршы

[1] Мөҗтәһид – үз тырышлыгы белән ислам чыганакларыннан нәтиҗәләр чыгаручы галим.

килсәләр дә, аларны инкяр итәргә, Коръән-хәдис юллары белән китәргә берәүнең дә хакы юк. Мөҗтәһиднең сүзе Коръән кәрим, хәдис шәрифләргә каршы килсә дә, мөҗтәһиднең сүзенә ияру кирәк; Коръән кәрим, Рәсүл хәдисе дәлил була алмый; мөҗтәһиднең сүзе генә катгый дәлил була».

Бу бәхәсләр, бу сүз көрәштерүләр, дини мәсьәләләргә каралып сөйләнсәләр дә, тормышыбызга зур тәэсир итте; һәркемдә фикер торгынлыгы хасил булды; олы кешеләр балалар хөкеменә, акыллы кешеләр ахмак, юләр хөкеменә керделәр, йомшаграк әйтсәк, шулар җөмләсенә керә яздылар.

Мәрхүм Мәрҗани кебек булдыклы, төптән уйлаучы затка бу рухи хәләт һәм тормыш хәләте тәэсир итте, ләкин киресенчә булган рәвештә. Ул коллык тормышының дөрес түгеллеген, ислам дине рухына бөтенләй каршы икәнлеген күрсәтүгә кереште.

Мәрхүм Мәрҗанинең бу турыдагы фикерләре һәрбер әсәрендә сизелгән кебек. «Назурә», «Әл-бәркыль-вәмид», «Мөкаддимәте вәфиятил-әсляф», «Әл-хикмәтел-бәлига» китапларында бик күп урын алалар.

Мисал өчен, бу турыдагы Мәрҗанинең каршы сөйләүләреннән бер кадәрен сөйләп үтик.

Мәрҗани хәзрәтләре әйтә: «Сез: «Дүрт мәзһәб бар, алардан узу ярамый», – дисез. Мәзһәбләр исә уннан артык. «Без Имам Әгъзам[2] мәзһәбендә», – дисез; шулай була торып, «Мохтасар»ларыгызда: «Имам Әгъзам болай дип әйтүен әйтә дә, имам Мөхәммәд яки имам Әбү Йосыф[3] фикеренчә фәтва бирелә», – дисез. Бу урында үзегезнең үзегезгә каршы килүегезне сизмисез».

Мәрҗани хәзрәтләренең моннан башка каршы сөйләүләре чиксез күп. Теләгән кешеләр мәрхүмнең әсәрләренә мөрәҗәгать итә белерләр.

Без бу урында тагын бер мисал китерү белән канәгатьләнәбез.

---

[2] Имам Әгъзам – имам Әбү Хәнифә.

[3] Имам Мөхәммәд, имам Йосыф – Әбү Хәнифә шәкертләре.

Мәрҗани хәзрәтләре «Кем Коръәнне үз фикере белән аңлата, шул үзенә утта урын әзерләсен» хәдисе турысында «Мөкаддимәте вәфиятил-әсляф»тә әйтә: «Исламның дөреслекне тикшерүчеләре бу ике караш ноктасыннан карап аңлыйлар:

1. Гарәп әдәбияты, ислам гыйлемнәре белән таныш булмаганнар Коръән кәримне аңлатсалар, ул кешеләр – гөнаһлылар.

2. Коръән кәримне тарткалап, сузгалап, үзенең күңел теләгенә, үзенең «мин әйттем»енә тарткан кешеләр шулай ук зур җинаять кылганнар җөмләсеннән булалар.

Дини гыйлемнәрне яхшы белгән, гарәп әдәбиятын белгән кешеләр Коръән кәримне, объектив күз белән карап, аңлатсалар, монда һичбер зарар юк.

Мәрҗани хәзрәтләре тәкълид бәласеннән котылып, шушы юлга аяк баса да, гомеренең ахырына кадәр хөр фикерендә дәвам итә. Үзе хак дип күргән нәрсәләрне дошманнарының һөҗүменнән курыкмый әйтә, яза.

Фикыһ мәсьәләләрендә, Имам Әгъзам хәзрәтләренең эзеннән бару белән бергә, хата дип тапкан урыннарда мөстәкыйль юл белән китә. Туры, хак дип тапса, кемнең сүзе булса да, кабул итә; Имам Әгъзам мәзһәбендә юк, дип тормый. Менә шул юл белән Мәрҗани халкыбызны ваемсызлык йокысыннан уятуга керешә, тырышуында нык булды. Менә уяну дәверебезнең башы, асылы, төп нигезе булган фикердә хөрлек юлын алга сөрүче, үләр хәлгә килгән тормышыбызга җан өрүче мәрхүм Мәрҗани хәзрәтләренә бүген йөз ел тулды.

Әҗәлдән элек үлемгә йөз тотуны, үлмәс борын каберен эзләүне теләмәгән кешеләргә шатлык көне – бүгенге көн. Бүгенге көн – иҗтимагый канун хөкеме буенча, тормыш, мәдәният юлында куәтләрен сарыф итеп, бетерә язып та, тагын да куәтле рәвештә яшәү өчен куәт җыеп ятучы татар милләтенең бәйрәм көне. Бүгенге көн – уянуыбызга, хакыйкатьтә, сәбәбче мәрхүм Мәрҗани хәзрәтләренең туган көне.

*«Йолдыз» газетасы. – 1915. – 9 гыйнвар. – Б. 2.*

*Исмәгыйль Габиди*

# Мәрҗани хәзрәтләре

Бүгенге көн һиҗри хисап белән төгәл менә йөз ел элек иде, Казан мөселманнары, бәлки, бөтен татар милләте өчен гыйльми, фикри хезмәтләре белән юлбашчылык итәр, даһилык кылыр бер сәләтле бала туды – Шиһабетдин Мәрҗани хәзрәтләре дөньяга килде.

Ул үсте, тәрбияләнде, олуг җәсәденең мөбарәк күкрәкләрен гыйлем нурлары белән нурландырып, хөрмәт һәм камиллеге, фикер һәм тойгылары милләтнең хәл һәм киләчәген бердәнбер идеяләреннән итеп кайгырткан хәлендә, шушы ук Казаныбыз, шушы ук халкыбыз арасына килеп, үткен һәм тирән мәгънәле, этрафлы һәм бай күзәтүле каләм һәм фикерләре белән хезмәткә тотынды, язды, сөйләде, эшләде. Кыскасы, милләтнең бәхете, аерым затларның ачылуы өчен матди һәм мәгънәви ярдәмнәрен багышлап, һәртөрле эшкә керешүләрдә булды.

Бу хезмәтләренә халык тарафыннан рәхмәтләр әйтелү, бу юлбашчылыгы өчен ихтирамнар белән куллары үбелү иң алда тотылган бер бурыч булса да, хәзрәтебез, вакыты белән, алмаз һәм якутлар бәрабәренә дә алышынмаслык булган кайбер фикерләре өчен халык авызыннан авыр сүзләр ишетте, шелтәләр алды. Бу хаксыз гаепләүләр, бу урынсыз сүзләрне сөйләми калырга аера белмәүче гади кешеләр аңлый алмаган кебек, үзләрен дин башлыклары [итеп] хисаплап, мәҗлеснең түрендә һәм халыкның агымы алдында утырган голяма [дип] аталганнарыбыз да изгелек итә белмәделәр, тыелмадылар.

Фәкать каһарман бер адәмнең батыр күкрәге алдында гайрәтле бер кул белән тотылган тимер калканнар, бәгырьләргә тукынып, тәннәрне зәһәрләр, сөякләргә тиеп каннарны эчәр өчен, дип ашкынып килгән мылтык ядрәләрен дә бик нык түземлеге белән кире кайтарырга, тәэсирсез калдырырга хезмәт иткән кебек, хәзрәтнең ныклыгы, кискен ният һәм тәвәккәллеге алдында да нинди генә бастырыкларда тетрәп калмыйча, буй-сынмыйча, уза алмадылар.

Шиһаб хәзрәт Казан мөселманнарының фикер куәсе ягыннан бик түбән бер вакытларында дөньяга килгән һәм халыкны шул наданлык һәм түбәнлегеннән коткару юлында һичбер киртәләргә карамый, башлаган эшен очлап чыгаруга бик нык осталык күрсәткән бер даһиебыз иде. Ул тырышты, чиктән тыш бер фидакярлек белән тырышты. Барлык хәлебез хакында озын-озын күзәтүләр белән төшенде. Ләкин халык һәм милләт, аны вакытында хакы белән танып, хезмәтен бәяләмәде. Бу хәл безнең ул вакыттагы аң һәм белемебезнең үсмәве һәм үсә белмәве, үсәргә теләмәве, тагын да дөресрәге, наданлык һәм фанатизмыбыздан иде.

Шуңа күрә бүгенге көндә инде Шиһабетдин хәзрәтне бөтен милләтебез хәтергә алып, рәхмәт һәм сәламнәрен юллап, пакь рухларына олыларыбыздан башлап та сабыйларыбызга кадәр хәер-догалар кылу белән үзләрен бәхетле саный.

*«Йолдыз» газетасы. – 1915. – 9 гыйнвар. – Б. 3–4.*

*Галиәсгар Гафуров*

# Шиһабетдин хәзрәт Мәрҗани исеменә. Үткән йөз елны искә төшерү

Безнең һәр көнебез – тарихи бер көн. Мәсәлән, бу 1333 ел рабигыль-әүвәленең 7 нче көне тәүлекнең тулган көне дә, атнаның тулган көне дә, айның тулган көне дә, һәрбер елның, ун елның, йөз елның һәм аннан артыкның тулган көне дә була. Ләкин вакытлар – алар бер аршин гына бит, алар бер нәрсәне үлчәгәндә генә кирәк булалар. Менә безнең артыбызда калган йөз ел бүген бер нәрсәне үлчәп бетерә. Ул безнең бүгенге көндәге баһадирыбыз шәех Шиһабетдин хәзрәт Мәрҗани хәзрәтенә үлчәү сала.

1333 – 7 рабигыль-әүвәл, 1333 – 7 рабигыль-әүвәл. Менә шул ике санның арасында хасыйл булган төп-төгәл бер йөз ел вакытны безнең Мәрҗани үзенең матди һәм мәгънәви [яктан] булуы белән тутырып тора.

Дөрес, ул бу озын йөз елның һәрбер җирен бертигез тутырмый. 1233 елның 7 рабигыль-әүвәлендә Ябынчы авылында, авыл мулласы Баһаветдин хәзрәтнең өендә бер ир бала туган. Ул баланың әһәмияте ул чагында, әлбәттә, берәүгә дә билгеле булмаган, ул чакта берәү дә: «Татар дөньясының ае Шиһаб хәзрәт Мәрҗани дөньяга килде», – дип белмәгән. Ләкин, хакыйкатьтә, ул шулай икән. Ул көн, ягъни 1233 елның 7 рабигыль-әүвәле татар дөньясының яңа ае туган көн икән. Ул бала үз ата-анасыннан башкага игътибарлы булмаган булса да, шәех Мәрҗанинең бар булуына хөрмәт йөзеннән, кешенең туган көненнән башланган тәрбиясенең тулылыгына тәэсире булырга тиешлегеннән, без ул чагында могтәбәр булмаган Шиһабетдинне хәзер дә тулы итеп

игътибарга алабыз. «Ул көндә атаклы булмаган бер авыл хәзрәтенең өендә туган бала бүгенге көнебезнең югары ягында сузылып яткан 100 елның теге башын үзе белән тутырган шул шәех Мәрҗани иде», – дибез. Ләкин без болай диеп кенә туктасак, аз булыр; ул көндә туган бала бер Шиһабетдин хәзрәт кенә түгелдер бит; ул көндә мең бала тугандыр, бәлки, шул Ябынчының үзендә дә аннан башка туган балалар булгандыр; без ул көндә туган мең кешене искә алмыйбыз да бары тик Шиһабетдин хәзрәтне генә искә алабыз. Моның сәбәбе нәрсә? Менә бүген безнең вазыйфабызга төшкән эш шул нәрсәне табу һәм шуны кешегә күрсәтү булса кирәк. Чыннан да, татар дөньясында Шиһаб хәзрәтне нәрсә таныттыра?

Менә шунда инде исәпләргә һәм дәрт күрсәтергә кирәк.

Шиһаб хәзрәтне ни өчен мактыйбыз? Ул татар дөньясының берәр черек җирен тазарттымы, ягъни ул яхшыландырулардан берәр төрле эш эшләдеме; ул берәр төрле кирәкле, файдалы эшкә нигез салдымы; я булмаса ул берәр черек җирне кисеп ташлап, яңа бер нәрсәгә җирлек әзерләдеме? Менә бу турыда тикшеренгән кешегә, әлбәттә, урын бар. Бу турыда төрле кеше сүз сөйләргә мөмкин һәм аның турында төрле сүз сөйлиләр дә.

Шиһабетдин хәзрәтнең билгеле бер һөнәр белән генә танылмавы, аның дәрте бер ноктага җыелмауданмы яисә ул ноктalar күп булганнанмы, анысын хәзергә әйтеп бетереп булмый.

Шиһаб хәзрәт дөньяда байтак озак яшәгән, ул бик күп төрле эшкә зиһен сарыф иткән, ул үзенең көчен төрле җиргә тараткан һәм шул таралган көчләрнең очы кая барып чыккан икән? Менә шул җеп очын табу кызыклы булыр иде, дип уйлыйбыз. Шиһаб хәзрәт татарны төзәтергә һәм тазартырга теләдеме, теләсә, кай юл белән теләде?

Кайберәүләр әйтәләр: «Шиһаб хәзрәт татар дөньясын бөтен ислам галәме белән бергә гасры сәгадәткә[1] кайтарырга теләде

[1] Гасры сәгадәт – Мөхәммәд пәйгамбәр һәм аның сәхабәләре яшәгән бәхетле заман.

һәм аның барча эшләре шул юлга юнәлгән иде», – дип. Чыннан да, бу сүзгә, әлбәттә, игътибар итәрлек галәмәтләр дә бар: Шиһаб хәзрәт бөтен барлыгы белән Сөннәтне кайгыртырга тырышкан. Ул үзенә Коръән белән Сөннәтне юлбашчы итеп тоткан һәм кешенең хәлен үлчәгәндә Сөннәткә муафыйк, Сөннәткә муафыйк түгел, бәлки бидгать, дигән кебек үлчәү белән тарттырган. Аның, иҗтиһад заманы үтмәде, дигәне дә шул нигездән туган булса кирәк. Чөнки ул күргән ки, замана һич туктаусыз үзгәреп тора, яңа эшләр берсе артыннан берсе туып тора, ул эшләрнең күбесен кабул итмәскә мөмкин түгел.

Икенчеләр: «Шиһаб хәзрәтне чын мәгънәсе белән реформатор иде», – дип баралар. Ул, әлбәттә. исламда зур бер көч һәм яхшы бер ысул таба иде. Аның шигаре: шул көч һәм ысулны эшләтеп, акыл һәм хәл таләп итүе даирәсендә һич туктаусыз үзгәрү һәм алга китү иде, диләр.

Боларның дәлилләре көчсез түгел. Иҗтиһад заманы үтмәде, дип әүвәлге юлда булу белән, бу соңгы юлда булуның араларында беркадәр якынлашу булса да, әһәмиятле аерма да юк түгел.

Шәех Мәрҗанинең кием-салымда, йөреш-торышта кыланышлы булуы, рәсем алдыруы, хаҗ юлында буфеттан аш ашап баруы, Мәниф пашаның өендәге нәфис һәйкәлгә тәмам эчке яктан каравы, губернаторлар һәм башка түрәләр, мөселман булмаган галимнәр белән самими катнашуда булуы аның заманага нинди күз белән каравын безгә яхшы гына аңлата.

Шиһаб хәзрәт күп нәрсәне тикшерде, ул бигрәк [тә] дини нәрсәләрне тикшерде. Аның утызга якын китаплары я туры дини мәсьәләгә бәйле яисә төбендә шул мәсьәләгә әйләнеп кайталар.

Без шәех Мәрҗанине халыкка якын кеше иде, халыкның моң-зарын уртаклашты, халыкны аякка бастырырга артык тырышлык сарыф итте, дип әйтә алмыйбыз. Шәех Мәрҗани Шиһаб хәзрәт, халыкка аңлашылмаган, халыктан ерак булган мәсьәләләрне тикшереп, гомер итте. Ул гомердә халык аңламый торган, гади халык түгел, җәмгыятьнең югары катлавы дигәне дә төшенми торган зур мәсьәләләр белән күбрәк бәйләнде.

Дөрес, зур галимнең зур мәсьәләләр белән бәйләнүе, әлбәттә, табигый, ул, бәлки, шулай тиештер. Ләкин шәех Мәрҗанине искә төшергәндә, аның турыдан-туры халык белән мөнәсәбәт тотмаганын бер телгә алып үтмәсәк, мөһим бер ноктаның күренми калу ихтималы бар.

Ул. Коръән бар ителгәнме-юкмы, сәхабәләрнең өстенлеге, галәмнең борынгылыгы, [намазда] бармак белән ишарә итү бәхәсләре халык арасында һичбер заман гомуми әһәмиятне алмады һәм моннан соң да алмаячактыр.

Шуның белән бергә, хәзерге мөселманнар һәм хәзерге халык өчен иң кыйммәтле шул шәех Мәрҗани Шиһабетдин хәзрәт. Хәзерге мөселманнарның һәр нәрсәләреннән артык бәя биргән ислам дине һәм Сөннәтне Шиһаб хәзрәт тимер дивар булып саклый иде. Шуның белән бергә, Шиһаб хәзрәт һәртөрле рәсми мәктәпләргә кереп укучыларны һәм һәртөрле сәнгатькә тотынучыларны гаепләүче түгел, бәлки хөрмәтләүче һәм яклаучы иде. Ул татарның тарихлы бер кавем икәнен җимерелмәслек бер рәвештә мәйданга куйды, ул исламның иң матур һәм иң якты ягын коры дәгъва белән генә түгел, үзенең бөтен яшәве һәм тормышы белән исбатлады.

Хатын-кызны дөньяга чыгару мәсьәләсендә Шиһабетдин хәзрәт соңгы милли теләкләрне канәгатьләндерерлек бернәрсә күрсәтмәсә дә, хатыннарны «озын чәч һәм кыска акыл» дип танымый иде. Аның хатыннарга ихтирам белән каравына сәбәп булырлык эшләре дә бар иде. Аның анасы Бибимәхбүбә абыстай догалар язучы булган, ул бер әбисе язган мосхәф шәрифкә дә ия булган, ул фәхешлек һәм бозыклык белән һичбер хатынын да һәм үзен дә пычратмаган. Шуның өчен ул хатыннарны телгә алырга туры килгән җирдә тәмам хөрмәт белән телгә ала.

Шиһабетдин хәзрәт Мәрҗани шәхси тормышында сөекле кеше булмаган, ул сөелергә теләмәгән. Ул үзенең бөтен торышы белән безгә салкынрак, ул үзенең тормышы белән бездән ераграк, ләкин ул татар улы татар иде. Ул чын мәгънәсе белән

мөселман иде. Ул үзенең бөтен барлыгы белән татарлык һәм мөселманлыгын исбатлап тора иде.

Шиһаб хәзрәтнең бик күп булган әсәрләреннән татарлар һәм мөселманнар үзләренә бик күп кирәк нәрсәләр табалар һәм табарлар.

Хәтер саклау өчен үзен күп имгәтмәгән ул туры затны заманасында сөймәгәннәр, аңламаганнар, танымаганнар. Ул чагында битараф карарлык күзләр йомык булып, ул затның бөтен барлыгын көнчеләре генә үз күзләре белән атып торганнар.

Үкенечкә каршы, ул вакыттагы шәхси көнләшүнең әсәре әле дә бетеп җитмәгән, хәзер дә шәех Мәрҗанигә, табыну мәртәбәсендә хөрмәт итәргә тиеш булган Кышкари һәм «динмәгыйшәтчеләр»[2] борынгыдан калган тәкълидләреннән[3] һаман да котыла алмыйлар.

Без һич какшамаган бер иман белән ышанабыз ки, вакытында җылы мәхәббәт белән сөя алмадык. Шиһабетдин хәзрәт Мәрҗани үзенең әсәрләре белән татар һәм мөселманнар арасында мәңге яшәр, бу мәрхүм хәзрәт татар һәм мөселман дөньясының ае урынын башкаларга бирмәс.

Шиһабетдин хәзрәт Мәрҗани әсәрләреннән чыгарып, йөзләрчә «Асар»лар, татар тарихлары, «Тәсхихе Корьән мәсьәләләре» һәм башкалар язылыр.

Шуның өчен без чын күңелебез белән ул олуг затны хөрмәт итәбез һәм күңелебездә булган хөрмәтле затларның түрен шул Мәрҗанигә бирәбез. Нәселенә, милләтенә кадерле булган ул затның хөрмәтле исеме мәңге калсын, дибез.

*«Кояш» газетасы. – 1915. – 9 гыйнвар. – Б. 3.*

[2] «Дин вә мәгыйшәт» журналын чыгаручылар һәм анда мәкаләләр язучылар.

[3] Тәкълид – дин галимнәренең сүзләренә сукырларча ияру.

*Гали Хәбиб*

# Мәрҗани һәм аның сүзләре

Бүген кайгылы көн. Чөнки бүген арабызда иң караңгы төнебездә шәм яккан, юл беткән вакытыбызда юл күрсәткән Мәрҗани хәзрәтләре юк, шуңа кайгырабыз.

Бүген шатлыклы көн. Чөнки моннан йөз ел элек бүгенге көндә үз арабыздан эшлекле Мәрҗани хәзрәтләре дөньяга килгән дә. Бүген аның рухына Коръән уку, дога кылу белән хөрмәтле булабыз, шатланабыз. Мәрҗани зур иде, олуг иде, бөек иде. Аның зурлыгын, аның бөеклеген мин дә раслыйм, аңа туры күз белән караган башкалар да таный, анда каршылык юк. Ләкин, кыска гына әйткәндә, аның бөеклеге кай ноктада иде? Менә бу ноктада төрле кеше төрлечә уйларга, төрле нәрсә күрсәтергә мөмкин. Башкалар теләсә кайсы фикердә булсыннар, минемчә, Мәрҗанинең бөтен бөеклеге, бөтен кешелеге, һәртөрле богаулардан азат хәлдә, һәр мәсьәлә хакында армыйталмый хакыйкатьне табарга тырышуында, тапкач, өстенә Каф тавы җимерелеп төшүдән дә курыкмыйча, аннан аерылмау, аны башкалар хәтере белән алмаштырмавында иде. Менә шушы сыйфат белән сыйфатланган, шушы корал белән коралланган, моннан нәкъ йөз ел элек туган безнең баһадир, динебез, тарихыбыз, наданлыгыбыз турысында байтак фикерләр сөйләгән, байтак юллар күрсәткән, көнне төнгә катып, байтак китаплар язган. Ләкин Мәрҗанинең күбрәк китаплары гарәпчә булу, аларның да байтагының нөсхәләре сатылып бетү, гадәте буенча, үз фикерләре төрле китабының төрле җиренә кыстырылган бу-

лу, аның сүзләре белән таныш булырга теләүчеләрнең байтагын читенлеккә төшерә. Шулай да Мәрҗани рухы белән таныш булырга теләүчеләр шушы көннәрдә нәшер ителәчәк «Мәрҗанинең тәрҗемәи хәле» исемле китапка һәм Ризаэтдин бине Фәхретдин җәнапларының Мәрҗани тәрҗемәи хәлен язган «Асар»ына мөрәҗәгать итсәләр, күп файда хасыйл итә алырлар.

Бүген Мәрҗани хәзрәтләренең туганына йөз ел тулган тарихи олуг көн. Бүген тел белән, ул булмаганда, каләм белән, ул булмаганда, күңел белән, Мәрҗани хәзрәтләренә хөрмәт күрсәтелә торган мөбарәк, зур көн. Мин дә шушы мөбарәк көн Мәрҗани рухына Коръән укып, дога кылына торган көн хөрмәтенә, турыдан-туры Мәрҗанинең үз китапларыннан алып, түбәндәге аның кайбер сүзләре белән «Кояш» [газетасы] битләрен мөкатдәс итмәкче булам.

**«Хаккыль-мәгърифә».** Хаклык һичбер вакытта яшерен булмый. Үземнең хаклык дип белгән нәрсәмне башкалар карашы сәбәпле ташлау гадәтем юк. Күфәдә, Гыйракта тумадым, табигатем дә мәгариф таратыр төсле түгел иде. Шулай да тутыйның сөйләве, күгәрченнең ритмлы итеп гөрләве кебек, мисалга каршы булып, мәгарифкә хезмәт иттем.

**«Әл-бәркыль-вәмидъ».** Гасры сәгадәттән[1] дүрт йөз еллар үткәч, хәнәфи галимнәренең соңгылары «ихтияты зоһр»[2] намазын [уйлап] чыгардылар. Минемчә, бу намазны, гәрчә кечкенә авылларда булса да, ваҗиб[3] итәргә юл юк.

**«Назурәтел-хак».** «Мөкаллиднең[4] дәлиле – мөҗтәһид[5] сүзе», – дигән мәшһүр сүз, шәригать дәлилен аңлаудан гаҗиз калган кеше, үзе каршында яхшы тапкан мөҗтәһид сүзен, баш-

[1] Гасры сәгадәт – Мөхәммәд пәйгамбәр һәм аның сәхабәләре яшәгән бәхетле заман.

[2] Ихтияты зоһр – җомга намазыннан соң кабат өйлә намазын уку.

[3] Ваҗиб – мәҗбүри.

[4] Мөкаллид – дин галимнәренең сүзләренә сукырларча иярүче.

[5] Мөҗтәһид – үз тырышлыгы белән ислам чыганакларыннан нәтиҗәләр чыгаручы галим.

калар сүзенә караганда алда тотып, шуның белән гамәл кылыр, мәгънәсендә. Әмма, мөҗтәһид булмаган кешегә тәкълид тиешле, мәгънәсендә түгел. Шәригать дәлилләре белән гамәл кылу бер мәзһәбтән икенче мәзһәбкә күчү [булып] саналмый.

«Мәзһәбтә ныклык кирәк», – диюдән: «Рәсүлүллаһ, сәхабәләр һәм изге дин галимнәре юлында булырга кирәк», – дигән мәгънәне аңлап: «Абсолют бер фәкыйһнең[6] фәтвасенә ябышырга тиеш», – [дигән] мәгънәне аңларга ярамый.

Аллаһ Тәгаләгә ышануның нигезен «Аллаһның күркәм исемнәре бар, алар белән дога кылыгыз» [Коръән, 7:180], «Аңа [Аллаһка] охшаш бернәрсә юк һәм Ул – Ишетүче, Күрүче» [Коръән, 42:11] дигән ике аять җиңел генә аңлатып бетерә.

Кәлям гыйлемендәге каршылыклы һәм бозык фикерләрне, гасры сәгадәттән соңгы бидгатьчеләр чыгарды.

**«Мөкаддимәте вәфиятил-әсляф».** Мөҗтәһид бүтән булмый [дип санау], кешене көферлеккә чыгару, ахырзаман якынаю, наданнарга голяма исемен тагу мәсьәләләре соңгы заман мөселманнары арасында гыйлем таралмауга зур сәбәп булды.

*«Кояш» газетасы. – 1915. – 9 гыйнвар. – Б. 3–4.*

[6] Фәкыйһ – ислам хокукы һәм шәригать мәсьәләләре белгече.

*Зәйнәп Кәрими*

# Мәрҗанинең йорт тормышындагы кайбер гадәтләре

Вакыт-вакыт Мәрҗанинең йортында булганлыктан, аның кайбер гамәлләрен бәян итеп китмәкче булам. Сүзгә керешкәнче шуны да әйтим ки, күргән, ишеткән һәм белгән нәрсәләргә кыйммәте вакытында бәя бирелми, шуңа күрә аңа әһәмият бирелми, шул сәбәптән, хәтердә калмый, калса да, бик аз, ярым-йорты, бер шәүлә күк кенә кала. Минем дә аның белән аралашудан калган хатирәләрем бик аз булуы белән бергә, әһәмиятсез була алыр. Моңа карамастан, гыйлем һәм гыйлем әһеленең кадерен белә торган газиз милләтем тарафыннан Мәрҗанинең тууына йөз ел тулу мөнәсәбәте белән ясалган юбилейга бөек агам Мәрҗани мәрхүм турындагы хатирәләремне язып уртаклашмакчы булам.

Без Мәрҗанинең ир һәм кыз туганнарының аерым-аерым авыллардан берничә кызлары идек. Үз вакыты белән Мәрҗани безнең аталарыбызга кунак булып килә иде. Бу вакыт һәркайсыбызның яшенә туры килгән күңелле һәм кызык сүзләр белән эндәшә, хәлләр сораша, безнең яшебезгә яраклы сүз һәм хикәяләр сөйләп көлдерә иде. Киткән вакытында, шулай ук үзебезчә әйтеп, кунакка чакырып китә иде.

Йортында булганда ашау-эчү Мәрҗани белән бер мәҗлестә була иде. Бу мәҗлесләрнең һәркайсында мөнәсәбәт чыгарып, төрле мәзәкләр сөйләп, мәҗлесне хушландыра һәм шунда булучыларны көлдерә иде.

Әстерхан күк җимешләре күп җирләрдән укырга килгән шәкертләре көз көннәрендә Мәрҗанигә бик күптөрле җимешне күчтәнәч итеп китерәләр иде. Ул боларны гаиләсе эчендә һәркемгә үзе бүлә һәм шуның эченнән үзенә дә өлеш аерып алып куя иде. Шулай ук шәһәр халкы һәм үзенә мөнәсәбәтле төрле тараф адәмнәреннән килгән кияү бүләге һәм Мәкәрҗә бүләге күк фруктыларны да бүлә, үзенә дә өлеш чыгарып комодына бикләп куя иде. Мондый нәрсәләрдән үзенә өлеш чыгармауны бер дә күтәрми иде. Кызларын тапшыргач, бертуганы Садретдин хәзрәт хатынына да: «Әсма миңа кияү бүләге куйсын, үземә аерым куеп җибәрсен», – дигән. Үзе кардәшләренә барганда яисә кардәшләренең балалары үзенә килгәндә, бу бүләкләрне әлеге балаларга биреп тота иде.

Без йортында булганда, кичләрен ул үзенең китапханәсендә уку белән мәшгуль, без йортның хатын-кызларга махсус бүлмәсендә җөй тегү, тирәк чыгару кебек эшләр белән мәшгуль була идек. Бервакыт, укуыннан бүленеп, китапханәдән чыгып, кыштыр-кыштыр безнең бүлмәгә таба килгәне ишетелә башлый. Без аның килүенә җыенып җитәр-җитми, безнең бүлмәгә килеп керә иде. Кулында әлеге фруктылар була һәм аны безгә бүлеп биреп шатландыра, шул мөнәсәбәт белән, тагын берникадәр без аңлардый кыйсса һәм мәзәкләр сөйләп көлдерә иде.

Аш мәҗлесе тәмам булганнан соң, калган икмәк һәм күмәч сыныкларын җыеп алып, бер тастымалга төрә, мискадагы калган шулпаның капкачын ябып, барын да үзе белән мәҗлестән алып китә һәм аларны китапханәсендәге китап шкафының бер җиренә җыеп куя иде. Кич, китап карап аргач, әлеге шулпа һәм икмәкләрне куйган урыннан алып, суык көенчә үзенең уку өстәленә җәя һәм үзеннән арткан булса, безнең бүлмәгә алып чыгып: «Мә, Галия, син тәмамла», – дип кызы Галия абыстайга бирә иде.

Ашаудан калган икмәк, күмәч катылары күк кавын, карбыз, алма кабыгы һәм боларның орлыклары кебек нәрсәләрнең барын да җыеп куя иде. Көтү кайткач, боларны үз кулы белән сы-

ерга биреп ашата, орлыклары белән тавык, чебеш һәм күркәләрне сыйлый иде.

Исраф һәм әйбернең әрәм булуыннан бик саклана, бу турыда игътибары шулкадәр иде ки, урам һәм ишегалды күк урыннарда тапталып, җиргә сеңеп беткән йомычка күк нәрсәләрне пәкесенең очы белән казып алып, ашханәнең тәрәзәсеннән: «Казан астына ягарсыз, әрәм итмәгез!» – дип эчтәгеләргә китереп бирә иде.

Йортында булганда күзенә күренгән ситса кисәкләрен бик вагына кадәр җыеп, үзенең китапханәсендәге шкафына бикләп куя иде һәм Ташкичүгә бертуганы мулла Садретдин хәзрәткә кунакка барганда бу кыйпылчыкларның берсен дә калдырмый үзе белән алып барып: «Мә, абзакай (бертуганы мулла Садретдин), моны Әсмага (бертуганының хатыны) бир, авыл карчыкларына бирсен, изү ясап, тагарлар», – дип бирә иде.

Бервакыт бер савыт балга тычкан төшеп, шунда үлгән. Моның өчен йорттагыларның бары да аптырашта калды: ташласаң, әрәм, куллансаң, җирәнгеч. Бөек агам мәсьәләне бик ансат бетерде: «Әй ахмаклар, аның нәрсәсе җирәнгеч? Сез кулланмасагыз, мин үзем кулланырмын. Аның пычрак урыны фәкать тычкан төшкән урын гына бит», – диде. Тычкан төшкән урынны пәке белән тирә-ягыннан юнып алды да, анысын түбә тимере астына куйды: «Бераздан бал кортлары алып бетерерләр, бер дә әрәм булмас», – диде. Ул дигәнчә, бераздан кортлар сарылды һәм алып та бетерделәр.

Безгә, аның туган кардәшләренең кыз балаларына, тәкъдирнең кушуы буенча, Казанда төпләнергә туры килде. Без һәркайсыбыз төрле йортларга урнашып, үз алдыбызга гомер итә башлагач та, Мәрҗани мәрхүм вакыты белән хәлебезне үзе килеп белә, вакыты булмаганда, кеше җибәреп белештерә иде. Вакыт-вакыт Казанда булган бөтен кыз кардәшләрен йортына җыя һәм мәҗлестә үзе рәислек итеп, мәҗлескә яраклы төрле мәзәкләр сөйләп, кыз туганнарын хушландыра. Атларын җиктереп, аларның барысы белән бергә: «Урамнарны әйләнеп, тамаша

итеп кайтыгыз!» – дип йөрергә чыгар иде. Вакыты белән һич уйламаганда: «Кунарга килдем, урын бирәсезме?» – дип, Казандагы безгә, кыз кардәшләренә, килеп кунгалый иде. Аларның берсе – бер, икенчесе икенче ашны яхшы пешерүдә Мәрҗани каршында өстенлек тапканга: «Фәлән ашны бик теләдем дә, сиңа килдем», – дип тә килгәләп куя иде.

Үзе кардәшлек хакын камил кайгырта, моның өстенлекләрен, сүз уңайлы килгәндә, безгә аңлата тора һәм үз арабызда кардәшлекне бик кайгыртырга куша иде.

Аллаһның рәхмәтендә булсын!

*«Кояш» газетасы. – 1915. – 9 гыйнвар. – Б. 4.*

# Эчтәлек

Кереш .................... 3

*Г. Ибраһимов.* Бөек остазыбызның кайбер әсәрләре
(юбилей мөнсәбәте белән тәнкыйть) .................... 10

*Г. Ибраһимов.* Бөек остазыбызның
тарихи бер тәнкыйте .................... 26

*Р. Фәхретдин.* «Мәрҗани» .................... 43

*Б. Шәрәф.* Мәрҗани хакында җавапларым .................... 46

*Г. Баттал.* Мәгънә һәм хакыйкать эзләүче галим .................... 52

*Г. Гыйсмәти.* Бүген йөз ел тулды .................... 57

*И. Габиди.* Мәрҗани хәзрәтләре .................... 61

*Г. Гафуров.* Шиһабетдин хәзрәт Мәрҗани исеменә.
Үткән йөз елны искә төшерү .................... 63

*Г. Хәбиб.* Мәрҗани һәм аның сүзләре .................... 68

*З. Кәрими.* Мәрҗанинең йорт тормышындагы
кайбер гадәтләре .................... 71

***Гайнутдинов Айдар Марсилевич***
(составитель)

**Иҗтиһад ишекләрен ачучы Мәрҗани:**
**Мәкаләләр җыентыгы**

**Открывший двери иджтихада Марджани:**
**Сборник статей**

*Научное издание*
*(на татарском языке)*

Оригинал-макет – *Л.М. Зигангареева*
Подписано в печать 4.09.2018 г. Формат 60×84 $^{1}/_{16}$
Усл. печ. л. 4,75. Тираж 200 экз.

Отпечатано с готового оригинал-макета

ЛОГОС
ИЗДАТЕЛЬСКИЙ ДОМ
*им. академика В.И. Андреева*

420108, г. Казань, ул. Портовая, 25а
Тел./факс: (843) 231-05-46,
231-08-71, 231-04-19
E-mail: citlogos@mail.ru
www.logos-press.ru

Сайт
Института истории
Академии наук РТ
Татаровед.рф